МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ГОСУДАРСТВЕННОЕ АВТОНОМНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ПРОФЕССИОНАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ИНСТИТУТ РАЗВИТИЯ ОБРАЗОВАНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

# ПАТРИОТИЧЕСКОЕ ВОСПИТАНИЕ МЛАДШИХ ШКОЛЬНИКОВ

## Из опыта работы учителей начальных классов Республики Татарстан

КАЗАНЬ
2015

**ББК 74.200.50**
**П 20**

**Руководители проекта:**
**Р.Г. Хамитов,** ректор ГАОУ ДПО ИРО РТ, канд.пед. наук, доцент
**Л.Ф. Салихова,** проректор по учебно-методической работе ГАОУ ДПО ИРО РТ, канд.пед.наук

**Составители:**
**Г. Р. Хамитова,** заведующий кафедрой дошкольного и начального общего образования, канд.пед.наук
**И. Т. Сагдиева,** старший преподаватель кафедры дошкольного и начального общего образования

Патриотическое воспитание младших школьников: из опыта работы учителей начальных классов Республики Татарстан / сост.: Г.Р. Хамитова, И.Т. Сагдиева. – Казань: ИРО РТ, 2015. – 160 с.

В предлагаемом сборнике представлен опыт учителей начальных классов Республики Татарстан, отражающий некоторые формы и методы организации патриотического воспитания в рамках празднования 70-й годовщины Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 годов. Материалы сборника будут полезны учителям начальной школы, воспитателям ГПД, педагогам дополнительного образования, специалистам методических служб.

© ГАОУ ДПО ИРО РТ, 2015

## СОДЕРЖАНИЕ


Введение ... 4
Патриотик тәрбия бирү – үзәктә ... 13
70 елда-70 хатирә (Эссе) ... 16
Дин мәдәнияте һәм этика дәресләре – заман таләбеме? ... 20
Р. Фәхреддин хезмәтләре – милли тәрбия бирүнең нигезе ... 22
Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә патриотик тәрбия бирү ... 29
Минем гаиләм тарихында – сугыш ... 33
Тамчы шоу «Моңлы бер җыр» ... 37
Сезнең тормыш – үзе батырлык (Сыйныф сәгате) ... 41
Хәтер (Класс сәгате эшкәртмәсе) ... 52
Әхлак тәрбиясе-мәңгелек төшенчә (урта сыйныф укучылары өчен түгәрәк эшчәнлеге) ... 56
Проект “Туган ягымны өйрәнәм” ... 68
Проектның төрле этапларында укучыларның эшчәнлеге ... 72
«Россия Федерациясенең дәүләт символлары» (2-3 сыйныфлар өчен сыйныф сәгате) ... 91
Ил саклар ир булып үсегез! (Фатих Кәримнең “Пионерка Гөлчәчәккә хат” поэмасы буенча дәрес-фикерләмә, 8 нче сыйныф) ... 97
Классный час «Солдатский треугольник» ... 106
Классный час «Мы помним» ... 110
Литературно-музыкальная композиция «Во имя тех священных дней» ... 119
Классный час «Класс глазами каждого» ... 126
Школьный музей как центр гражданско-патриотического воспитания ... 130
Классный час-экскурсия в школьном музее Военно-Морского флота на тему:«В преддверии великой победы» ... 138
Патриотическое воспитание в начальной школе как средство формирования социальной и личностной культуры младшего школьника ... 144
Проектная работа «Мой прадед – автор гимна Татарстана» ... 156

# ВВЕДЕНИЕ

Патриотизм является стержнем всех гражданских качеств личности. Сущность понятия «патриотизм» (от греческого patris – родина) включает в себя любовь к Родине, земле, где родился и вырос, гордость за исторические свершения своего народа.

Концепция духовно-нравственного развития и воспитания личности гражданина России рассматривает как неотъемлемую часть деятельности общеобразовательных организаций процесс воспитания гражданина и патриота.

Под патриотизмом в Концепции понимается чувство и сформировавшаяся позиция верности своей стране и солидарности с её народом. Патриотизм включает чувство гордости за своё Отечество, малую родину, т.е. край, республику, город или сельскую местность, где гражданин родился и рос. Патриотизм включает активную гражданскую позицию, готовность к служению Отечеству.

Задачи духовно-нравственного воспитания школьников определены как ожидаемые результаты в логике требований к личностным результатам общего начального образования и предусматривают в том числе:

*Воспитание гражданственности, патриотизма, уважения к правам, свободам и обязанностям человека:*

- элементарные представления о политическом устройстве Российского государства, его институтах, их роли в жизни общества, о его важнейших законах;
- представления о символах государства – Флаге, Гербе России, о флаге и гербе субъекта Российской Федерации, в котором находится образовательное учреждение;
- элементарные представления об институтах гражданского общества, о возможностях участия граждан

в общественном управлении;

- элементарные представления о правах и обязанностях гражданина России;
- интерес к общественным явлениям, понимание активной роли человека в обществе;
- уважительное отношение к русскому языку как государственному, языку межнационального общения;
- ценностное отношение к своему национальному языку и культуре;
- начальные представления о народах России, об их общей исторической судьбе, о единстве народов нашей страны;
- элементарные представления о национальных героях и важнейших событиях истории России и её народов;
- интерес к государственным праздникам и важнейшим событиям в жизни России, субъекта Российской Федерации, края (населённого пункта), в котором находится образовательное учреждение;
- стремление активно участвовать в делах класса, школы, семьи, своего села, города;
- любовь к образовательному учреждению, своему селу, городу, народу, России;
- уважение к защитникам Родины;
- умение отвечать за свои поступки;
- негативное отношение к нарушениям порядка в классе, дома, на улице, к невыполнению человеком своих обязанностей.

Актуальность формирования чувства патриотизма в младшем школьном возрасте нашла свое отражение в содержании Федерального государственного образовательного стандарта начального общего образования. В нем указывается, что портрет выпускника начальной школы включает в себя такие личностные характеристики, как любовь к сво-

ему народу, краю и Родине; уважение и принятие ценности семьи и общества; любознательность, активность и заинтересованность в познании мира и т. д. Освоение учащимися основной образовательной программы начального общего образования должно, в частности, иметь и личностные результаты, отражающие уровень сформированности основ российской гражданской идентичности, чувства гордости за свою Родину, российский народ и историю отечества, осознания своей этнической и национальной принадлежности в контексте принятия ценностей многонационального российского общества и другое.

В настоящее время воспитательное пространство начальной школы формируется по пяти направлениям:

*1. Урочная деятельность.*

*2. Внеурочная деятельность (культурные практики).*

*3. Внешкольная деятельность (социальные и культурные практики).*

*4. Семейное воспитание.*

*5. Изучение культурологических основ традиционных российских религий.*

<u>Урочная деятельность.</u> Воспитательные задачи должны быть интегрированы в содержание учебных предметов. На учебное содержание необходимо смотреть не только со стороны традиционных дидактических принципов (научности, системности, последовательности и т.д.), не менее важными являются принципы культуросообразности, культурогенеза, ценностной ориентации образования, нравственного развития личности. Система базовых национальных ценностей не только отражается в содержании обучения, но и сама оказывает существенное влияние на его организацию.

Внеурочная деятельность. Базовые ценности должны быть отражены в содержании внеурочных воспитательных мероприятий: праздников, викторин, выставок, дискуссий,

игр и т.д., – а также в деятельности кружков, секций, клубов и других форм дополнительного образования. Основной педагогической единицей внеурочной деятельности является культурная практика – организуемое педагогами и воспитанниками культурное событие, участие в котором расширяет их опыт конструктивного, творческого поведения в культуре.

Внешкольная деятельность. Внешкольные мероприятия: экскурсии, разнообразные десанты, сборы помощи, благотворительные, экологические, военно-патриотические мероприятия, полезные дела и т.д. – организуются в пределах целостного, социально-открытого образовательного пространства. Основной педагогической единицей внешкольной деятельности является социальная практика – педагогически моделируемая в реальных условиях общественно-значимая задача, участие в решении которой формирует у педагогов и воспитанников социальную компетентность и опыт конструктивного гражданского поведения. Социальные практики позволяют школьнику получать опыт нравственно значимого поступка, переводя содержание национальных ценностей в план общественно значимой деятельности. В организации и проведении социальных практик могут принимать участие не только педагоги и школьники, но и иные субъекты гражданской деятельности: ветераны, деятели культуры и спорта, представители социальных служб и т.д.

Задача управления воспитанием в начальной школе, в сопоставлении с последующими ступенями общего образования, решается органично в силу того, что классный руководитель является и основным организатором школьной жизни учеников.

Задача классного руководителя в начальной школе - создание социально открытого пространства, когда каждый педагог, сотрудник школы, родители разделяют ключевые

смыслы духовных и нравственных идеалов и ценностей, положенных в основание данной программы, стремясь к их реализации в практической жизнедеятельности:

- в содержании и построении уроков;
- в способах организации совместной деятельности взрослых и детей в учебной и внеучебной деятельности; в характере общения и сотрудничества взрослого и ребенка;
- в опыте организации индивидуальной, групповой, коллективной деятельности учащихся;
- в специальных событиях, спроектированных с учетом определенной ценности и смысла;
- в личном примере ученикам.

Классный руководитель обеспечивает:

- педагогическую поддержку решения школьниками межпредметных воспитательных задач;
- подготовку и проведение внеклассных и внешкольных воспитательных мероприятий;
- участие в добровольных детских разновозрастных организаций различной направленности;
- координацию программ семейного и школьного воспитания;
- содействие в решении индивидуальных проблем духовно-нравственного развития детей.

Воспитание чувств патриотизма на каждом возрастном этапе имеет свои особенности.

Дети младшего школьного возраста очень восприимчивы, любознательны, отзывчивы, они легко откликаются на все инициативы, искренне сочувствуют и сопереживают. Данный отрезок жизни человека является наиболее благоприятным для эмоционально-психологического воздействия на ребенка, так как его образы восприятия очень сильны и ярки. Это позволяет задерживать их в памяти надолго, а иногда и на всю жизнь, что очень актуально в воспитании

патриотизма.

Анализ проблем, связанных с патриотическим воспитанием, позволяет утверждать, что реализация патриотического воспитания в начальной школе должна осуществляться с учетом особенностей младших школьников. В исследованиях отечественных ученых отмечается, что данному возрасту соответствует психологические особенности, которые необходимо учитывать при осуществлении патриотического воспитания:

– данный возрастной период характеризуется интенсивным накоплением знаний, их выборочным усвоением, доверчивым подчинением авторитету учителя, повышенной восприимчивостью, внимательностью (Н.С. Лейтес);
– учащиеся начальных классов осознают свое поведение, сравнивают себя с другими;
– в данном возрасте совершенствуется нервная система, быстро развивается психика ребенка;
– восприятие младших школьников отличается неустойчивостью и неорганизованностью, остротой и свежестью, «созерцательной любознательностью»;
– внимание непроизвольно, недостаточно устойчиво, ограничено по объему;
– младший школьный возраст начало общественного бытия человека как субъекта деятельности, которая является фактором становления новообразований личности (Л.И. Божович).
– данный возраст является наиболее сензитивным периодом для воспитания положительных черт личности, в том числе и патриотизма.

Податливость, внушаемость детей младшего школьного возраста, их доверчивость, склонность к подражанию и огромный авторитет, которым пользуется учитель, создает благоприятные предпосылки для успешного решения про-

блемы патриотического воспитания учащихся начальных классов. Своеобразие патриотического воспитания младших школьников предопределяется спецификой нравственного развития личности младшего школьника в целом. Эта специфика обуславливается общими особенностями этого возраста – весьма сильная восприимчивость младшего школьника к внешним влияниям, большая возбудимость его эмоциональной сферы, предрасположенность к усвоению нового, яркость восприятия. Младшие школьники мыслят образами, эмоционально воспринимают ярко окрашенные события и факты, особенно облеченные в художественную форму. Таким образом, организуя работу по воспитанию патриотических чувств, обеспечивая ее педагогическую эффективность, учителю необходимо осуществлять работу на высоком эмоциональном уровне. Для организации системы патриотического воспитания можно воспользоваться перечнем примерных видов деятельности и формы занятий с учащимися начальной школы, предлагаемых в Примерной программе воспитания и социализации обучающихся:

*Воспитание гражданственности, патриотизма, уважения к правам, свободам и обязанностям человека:*

- получение первоначальных представлений о Конституции России, ознакомление с государственной символикой – Гербом, Флагом Российской Федерации, гербом и флагом субъекта Российской Федерации, в котором находится образовательное учреждение (на плакатах, картинах, в процессе бесед, чтения книг, изучения предметов инвариантной и вариативной частей базисного учебного плана);
- ознакомление с героическими страницами истории России, жизнью замечательных людей, явивших примеры гражданского служения, исполнения патриотического долга, с обязанностями гражданина (в процессе бесед, экскурсий, просмотра кинофильмов,

путешествий по историческим и памятным местам, сюжетно-ролевых игр гражданского и историко-патриотического содержания, изучения основных и вариативных учебных дисциплин);

– ознакомление с историей и культурой родного края, народным творчеством, этнокультурными традициями, фольклором, особенностями быта народов России (в процессе бесед, сюжетно-ролевых игр, просмотра кинофильмов, творческих конкурсов, фестивалей, праздников, экскурсий, путешествий, туристско-краеведческих экспедиций, изучения вариативных учебных дисциплин);

– знакомство с важнейшими событиями в истории нашей страны, содержанием и значением государственных праздников (в процессе бесед, проведения классных часов, просмотра учебных фильмов, участия в подготовке и проведении мероприятий, посвященных государственным праздникам);

– знакомство с деятельностью общественных организаций патриотической и гражданской направленности, детско-юношеских движений, организаций, сообществ, с правами гражданина (в процессе посильного участия в социальных проектах и мероприятиях, проводимых детско-юношескими организациями);

– участие в просмотре учебных фильмов, отрывков из художественных фильмов, проведении бесед о подвигах Российской армии, защитниках Отечества, подготовке и проведении игр военно-патриотического содержания, конкурсов и спортивных соревнований, сюжетно-ролевых игр на местности, встреч с ветеранами и военнослужащими;

– получение первоначального опыта межкультурной коммуникации с детьми и взрослыми – представителями разных народов России, знакомство с особенностями

их культур и образа жизни (в процессе бесед, народных игр, организации и проведения национально-культурных праздников);

– участие во встречах и беседах с выпускниками своей школы, ознакомление с биографиями выпускников, явивших собой достойные примеры гражданственности и патриотизма.

В предлагаемом сборнике представлен опыт учителей начальных классов Республики Татарстан, отражающий некоторые формы и методы организации патриотического воспитания в рамках празднования 70-й годовщины Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 годов. Материалы сборника будут полезны учителям начальной школы, воспитателям ГПД, педагогам дополнительного образования, специалистам методических служб.

**Источники:**


1. Концепция духовно-нравственного развития и воспитания личности гражданина России в сфере общего образования: проект/ А. Я. Данилюк, А. М. Кондаков, В. А. Тишков. Рос. Акад. Образования. – М.: Просвещение, 2009.
2. Сайт Минобрнауки России [Электронный ресурс]. — URL: http://www.edu.ru/db-mon/mo/Data/d_09/m373.html.
3. Мусс Г.Н. Патриотическое воспитание: потенциал внеурочной деятельности на ступени начального и основного общего образования. – Saarbrucken, Germany: LAP LAMBERT Academic Publishing GmbH&Co. KG. 2011.
4. Жданова, Н. М. Современные проблемы патриотического воспитания младших школьников / Н. М. Жданова //Педагогическое образование: традиции, инновации, поиски, перспективы: междунар.

заоч. науч.-практ. конф. (Шадринск, 10 дек. 2010 г.) / Шадринский гос. пед. ин-т. – Шадринск: Шадр. Дом Печати, 2011. – С .154–159.
5. Швецова Елена Викторовна, Формирование патриотизма у младших школьников средствами народной педагогики : диссертация ... кандидата педагогических наук : 13.00.01 / Швецова Елена Викторовна; [Место защиты: Чуваш. гос. пед. ун-т им. И.Я. Яковлева]. – Чебоксары, 2010. – 255 с.: ил. РГБ ОД, 61 10-13/972.

## ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ БИРҮ – ҮЗӘКТӘ

**Миннегалиева Кадрия Миргарифан кызы,**
**Түбән Кама районы Югары Чаллы урта белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы**

Гәҗит битләреннән әби-бабайларның җан авазы салынган хатларын укырга яратам. Нинди генә авыр язмышлы кешеләр юк араларында. Авыр сугыш еллары, ачлык-хәерчелек, толлык-ялгызлык – берсен дә читләтеп узмаган. Юк, хатларында зарлану юк аларның, хәзерге рәхәт тормыш белән чагыштыру, булганына шөкер итү, гыйбрәт өчен язылган язмалар алар. Илен яраткан, халыклар дуслыгы белән яшәгән, төзегән, җитештергән буын булган безнең әби-бабайларыбыз. Физик хезмәттән башы чыкмаган, мәктәп, телевизор, радио дигәненең төшенә дә кермәгән кешеләрдә (бигрәк тә авыл җирендәге) патриотик рух каян килгән, безнеңчә әйтсәк, ничек тәрбияләнгән ул рух аларда?!

Федераль дәүләт белем бирү стандарты үз халкын, туган ягын, Ватанын яратучы һәм хөрмәт итүче шәхес булдыруга юнәлдерелгән. Шул максаттан без – укытучылар – балаларны 1 сыйныфтан ук төрле тәрбия чаралары

ярдәмендә тәрбиялибез. Сыйныф сәгатьләре, бәйрәмнәр, очрашулар – укучыларда тәрбияви эз калдырырга тиеш. Туган җирне, олыларны хөрмәтләргә, илеңә өчен утка-суга керергә, хезмәтне сөяргә өйрәтү хәзер укытучылар өчен җиңел түгел. Янәшәдә кызыктыргыч параллель дөнья - интернет челтәре. Чүп-чар кинолар белән чуарланган телевизор экраныннан да бала совет фильмнарын түгел, ә чит ил боевикларын карый. Хәер, хәзерге үзебезнең сериаллар да үтереш-суеш, байлык туплау темасын гына чагылдыра бит.

Мәктәбебездә Ватанны саклаучылар көне алдыннан һәр елны "Аждаган" уеннары үткәрелә. Ике төркемгә бүленгән укучылар үзләрен чын солдатлар итеп тойсыннар өчен командирлар итеп авылыбызның әфганчыларын чакырабыз. Балаларның чын-чынлыклап үзләренең байракларын югалтмаска, "чикләрен" сакларга, миналы кырдан "шартламыйча" үтәргә тырышуларын, "яралы" иптәшләренә оста итеп беренче ярдәм күрсәтүләрен күрү – күңелдә шатлык һәм өмет хисе тудыра. Бер генә көнгә компьютер – телефоннарыннан, планшетларыннан арынып шундый "чын" уен уйнау – аларга да күңелле.

Күзәтүләремнән чыгып, шуны әйтә алам: "Аждаган" уеныннан соң укучы малайларның армиягә китеп, хәрби бурычны үтәү теләге бермә-бер үсә. Бу инде хәзерге буында үлеп барган патриотлык хисләрен әз генә булса да ояту.

Сыйныфым белән еш кына туган илебез турында әңгәмәләр үткәрәм. Балалардан "Туган илебезне, авылыбызны яратасызмы?" дип сорыйм. Әлбәттә, бер авыздан дежур җавап: "Яратабыз!" дигәнне ишетәм. Ә менә "Кайсы илдә яшәр идегез?" дип сорагач, ярты сыйныф баласы чит илләрне санап китүенә аптырамадым. "Басу капкалы элекке авыл тормышын сагынам"- дип утырган 80 яшьлек әбигә дә гаҗәпләнмим. Әбием мул тормышта яшәсә дә, гадилекне, хәзергечә әйтсәк "натуральный" тормышны сагынса, безнең әзергә-бәзер яшәгән балаларны, Пушкин әкиятендәге туй-

мас әби сыман, һаман чит дөнья байлыгы, рәхәт тормыш кызыктыра. Моңа җавап итеп мин аларга татар халкының патриот уллары Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Газинур Гафиятуллин батырлыкларын укучыларыма сөйләдем. Шагыйрь – герой Муса Җәлилнең һәм аның иптәшләренең илебезне сатмавы, батырлыклары бөтен татар халкына , татар иленә дан китерде, дөнья халыклары арасында татарларның дәрәҗәсен күтәрде. Балаларым әсәрләнеп тарих тыңлый, ә мин күңелемнән һәрберсенең әби-бабайларын барлыйм. Каршымда утырган 20 укучының 7се сугыш ветераны оныгы. Горурланыр кешеләре бар. Хәзерге буын балалалары да ата-ана күрке генә түгел, ә ил горурланырлык булып үссеннәр иде.

Минем фикеремчә, патриотик рухтагы, хезмәт сөючән, әдәпле балалар үстерү өчен, бәлки мәктәпләрдә элеккеге башлангыч хәрби әзерлек (НВП) дәресләрен кире кайтарыргадыр һәм хезмәт дәресләренә дә игътибарны арттырырга кирәктер.

Патриотик рухны үстерүче әһәмиятле темаларның берсе: “Бөек Ватан сугышы”. Тиздән Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итәбез. Сугышны үз күзләре белән күргән ветераннарыбызның саны елдан-ел кими. Алар исән чакта очрашулар үткәрү, укучылар белән өйләренә барып хәлләрен белүне оештыру – сыйныф җитәкчесенең төп бурычы дип саныйм мин. Хәзер бит техника заманы, алар сөйләгәнне диктофонга яздырып алсак, ул язмалар буыннан-буынга тапшырылыр иде. Чөнки Бөек Ватан сугышында күп югалтулар аша ирешелгән җиңүнең ничек килүен беркем дә, беркайчан да онытырга тиеш түгел.

Арабыздан киткән сугыш ветераннарын тылда хезмәт иткән әби-бабайлар алыштырды. Яшьләргә әйтер сүзләре күп аларның. “Тамчы тама-тама бозны тишә” – дигәннәр бит. Бәлки, олыларның сөйләгән хикмәтле сүзләре балаларыбызның “күгәргән” күңелләрен әз генә булса да чистартып, үзенең орлыгын салыр әле.

## 70 ЕЛДА – 70 ХАТИРӘ (ЭССЕ)

**Нажия Шиһапова,**
**Апас районы Сатламыш урта мәктәбенең**
**югары категорияле башлангыч сыйныф укытучысы**

1941 ел. 22 июнь. Таңатып килә. Гүзәл авыллар, шәһәрләр тыныч йокыда. Әниләренең җылы куенында тәмле төшләр күреп нәни сабыйлар изрәп йоклыйлар. Шул вакытта канга туймас фашист этләре безнең чикне бозып авылларны, шәһәрләрне үлем утына тоталар. Бөек Ватан сугышы башлана. Берни белми изрәп яткан сабыйлар зәңгәр күккә карап хәрәкәтсез калалар. Зәңгәр күкне канлы корым каплый.

Аяусыз сугыш башлана. 1941 нче елда башланып киткән Бөек Ватан сугышы тарихта аерым урын алып тора. Төрле революцияләр, интервенция, колхозлашу, Сталин репрессияләре белән тәмам йончыган, таланган, хәерчеләнгән совет халкын янә бер кат ныклыкка сыный ул, яшәү-яшәмәвебезне көн тәртибенә куя.

Илебезгә көчле һәм рәхимсез дошманга каршы торырга туры килә. Сугышның беренче көненнән үк дошманга каршы көрәшкә бөтен халык күтәрелә. Фронттагы сугышчыларга да, басып алынган җирләрдә дошманга каршы сугышкан партизаннар һәм подпольщикларга да, фронтны бөтен кирәк-ярак белән тәэмин итеп торган тыл хезмәтчәннәренә дә бик авырга туры килә.

Якташларыбыз да бер мең дүрт йөз унсигез көн һәм төн дәвамында киерелгән җәя шикелле дәһшәтле вакыйгалар һәм моңарчы күрелмәгән язмыш сынавы чолганышында калалар. Татарстан Республикасы Апас районыннан Ватан сагына, ут эченә 9112 кеше китә. Әмма күбесенә туган-үскән нигезләренә кире әйләнеп кайтырга насыйп булмый шул, алар Ватан азатлыгы, Европаны фашизм тырнагыннан коткару өчен изге яуда башларын салып, чит-ят җирләрдә

мәңгелеккә ятып калалар. Шул исәптән Апас төбәгендә дә күп гаиләләрне кайгы җиле читләтеп узмый, һәр йорт диярлек сугыш ачысыннан боегып, ямансулап кала.

Әмма уртак Ватан капкасын шакыган афәт никадәр генә куркыныч булмасын, ул дәһшәтле көннәрдә шәһәр-авылларыбыз фронт ихтыяҗларын кайгыртып яши.

"Барысы да фронт өчен, барысы да Җиңү өчен!" дигән лозунг ирләрен сугышка озаткан хатыннарның, әле борын асты да кипмәгән үсмерләрнең-кыскасы, тылда калган һәркемнең яшәү принцибына әйләнә.

Авыр, бик авыр еллар.... Ләкин түзгәннәр, иреннәреннән кан саркыганчы түзгәннәр. Дошманны тизрәк туган җиребездән куып чыгару. Менә шушы олы максатка ирешүдә безнең Карамасар авылы халкы да йөрәкләреннән өзеп улларын, кызларын биргән. Авыл язмышы ил язмышына кушыла.Безнең Карамасар авылыннан бу сугышта 142 кеше катнаша. Шуларның 86 сы сугыш кырында ятып кала. Сугыштан барлыгы 56 кеше әйләнеп кайта. Ләкин елдан-ел ветераннарыбыз сафы да сирәгәя бара. Бу Җиңү зур корбаннар аша килде һәм менә 70 ел инде илебез халкы тыныч тормышта яши. Дүрт ел сугыш дәвамында халкыбыз тудырган зур батырлыклар һәм кичергән зур газаплар 70ел буена да, 100 ел буена да онытырлык түгел!

Фашизмны Җиңү бәйрәмен билгеләп үткән язгы матур көннәрдә без исә ветераннарны хөрмәтлибез, һәлак булган батырларны ихтирам белән искә алабыз.

Онытылмый беркем дә!
Онытылмый берни дә.
Бабайларның, әтиләрнең
Дан юлыннан атлыйбыз.
Өлкән буын батырлыгын
Йөрәкләрдә саклыйбыз!

Әйе, Бөек Ватан сугышы тәмамлануга быел 70 ел тула. Илебездә ел саен 9 май – Җиңү көнен билгеләп үтәбез.

Ул көн бәйрәм генә түгел, истәлекләр һәм хатирәләр көне дә. Җиңү бәйрәмнәре тагын шаулап узар. Ләкин кешеләр йөрәгендә сугыш калдырган яра-җәрәхәтләр һаман да сыкрый әле. Йөрәк яраларыбыздан һаман да кан саркып тора. Сугыш афәтен башыннан кичергән кешеләр кабат сугыш булуын беркайчан да теләмәсләр. Шунлыктан илебез халыклары сугышка каршы. Кешелек дөньясы тарих сабакларын онытырга тиеш түгел.

Шушы сугышта катнашып, әйләнеп кайтучы 56 ветеранбызның – бары берсе генә- хәзерге вакытта безнең арада – Әхтәмова Тәнзилә Шәнгәрәй кызына без бик рәхмәтле. Аның белән һәр ел очрашу үткәрәбез. Сугышның ачысын-төчесен татыган ветеранбызның инде чәчләренә ак бәсләр кунган. Сугыш аның күңелендә һич төзәлмәслек тирән яра, хатирә калдырган. ”Яшьләр сугышны күрмәсеннәр иде, ходай тәгалә андый авырлыкларны, күз яшьләрен күрсәтмәсен, киләчәк буыннар да ата-ана тигезлеге белән, озын-озак яшәп бәхетле булсыннар, дөньялар тыныч булсын!” – ди ул.

Ирләре, уллары, туганнары зур батырлыклар күрсәткәндә, тылдагы хатын-кызларыбыз үзләрен аямыйча эшлиләр.Тылдагы хатын-кызларның батырлыгы сугыш кырында туган батырлыкка тиң. Әйе, авылда картлар, хатын-кызлар һәм балалар гына кала. Ә тормышны алып барырга кирәк иде-игенен дә игәргә, балаларны да ачялангач итмәскә, сугышка төрле җылы киемнәр дә әзерләп җибәрергә, гомер буе бетмәс төсле тоелган налогын да илтеп түләргә кирәк булган. Ләкин алар сынатмаганнар, сыгылмаганнар. Бөтен булган физик авырлыкларга түзәр идең әле, авылларга кара пичәтле кәгазләр агыла. Алма кебек хатыннар балаларын кочаклап ирсез, сабыйлар әтисез, җиләк кебек кызлар ярсыз калалар. Шушы сугыш вакытында тол калган һәм хәзерге вакытка кадәр исән-сау булып яңа гына гүр иясе булган әбиләребез: Әминова Сәкинә, Гайнуллина

Мәүҗүдә, Шәяхмәтова Сәүдә әбиләр. Еллар картайтса да аларның йөрәкләре, күңелләре яшь, яшәү дәртләре сүнмәгән иде әле. Аларның тормыш юллары-без яшьләр өчен дә батырлыкка тиң. 103 яшьлек Карамасарның Акъәбие Мәүҗүдә әби Гайнуллина икенче гасырлык гомеренә аяк баскан иде. Моны бәхет, язмыш дими ни диярсең.

Сугыш беткәч тә, тыл каһарманнары төнне көнгә, көнне төнгә ялгап эшләүләрен дәвам итәләр, чөнки илдәге сугыш китергән хәрабәләрне торгызырга кирәк. Алар тагын ил язмышына кушылып хезмәткә җигеләләр. Алар арасында хәзерге көнгә кадәр намус белән үз хезмәтләрен башкаручылар байтак. Күпләре инде гаиләдә олы ихтирамлы кешеләр,балаларының таянычы, оныкларының юанычы. Алар әле дә олы йөрәкле, нык бәдәнле, саф күңелле әүлия затлар, сугыш чоры кешеләре!

Картаймагыз әле, ветераннар,
Картаймагыз, әй,тынгысыз җаннар!
Сезгә тиеш әле бик күп язлар,
Сезгә тиеш әле бик күп назлар. (Хәкимҗан Халиков)

Батырлык ул – рухи матурлык. Әнә шуңа күрә дә халкыбыз кеше күңеленең рухи бөклеген югары бәяләгән. Батырларның кылган изге гамәлләре ,данлы исемнәре әкиятләргә күчкән, җыр- дастаннарга кергән. Каһарманлык, чорлар аша кичеп, бүгенге көннәргә килеп җиткән. Халкыбыз улларының һәм кызларының Бөек Ватан сугышы чорында күрсәткән тиңдәшсез фидакарьлеге дә күңелләрдән мәңге җуелмас. Шул олуг Батырлык алдында безнең дәвер кешеләре генә түгел, киләсе гасырларда яшәүчеләр дә башларын иярләр әле.

Сугыш ялкыны безнең дөньяны
Чолгап алмасын яңадан
Сакла,сакла тынычлыкны,
Дан тынычлыкка, дан, дан, дан!
Бу дәхшәтле сугыш газапларын

Күргәне юк безнең күбебез.
Күрмәгәнгә ходай күрсәтмәсен,
Мәңге аяз булсын күгебез.
Әти-әни,әби-бабайларның
Кичергәнен кабат кичермик
Бу тынычлык, якты матур тормыш-
Барысы да безнең өчен бит!

## ДИН МӘДӘНИЯТЕ ҺӘМ ЭТИКА ДӘРЕСЛӘРЕ – ЗАМАН ТАЛӘБЕМЕ?

**Миннегалиева Кадрия Миргарифан кызы,**
**Түбән Кама районы Югары Чаллы урта белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы**

Рәхәт, мул тормышта яшибез. Тик анда-монда “шартлатылган” дигәнне ишеткәч кенә, куркыныч дөньяның да янәшәдә генә икәнен аңлыйсың. Терроризм фетнәсе елдан-ел арта. Террорның дине юк, дип әйтеп торсалар да, халыкның фикере икегә бүленгән. Исламчылар – террорчыларга тагылган ярлык инде ул. Динне аңламаган кешеләрнең ислам диненә карата каршы фикер уятырга бер сәбәп булып тора бу.

Безнең Татарстаныбызда толерантлык яши: дини җәмгыятьләр үзара тату мөнәсәбәттә, ярдәмләшеп – киңәшләшеп торалар. Ләкин шушы дуслыкка аяк чалучы көчләр юк дип әйтеп булмый. Толерантлыкны саклау өчен яшьтән үк аны балаларга аңлату зыян итмәс иде. Шул максаттан мәктәпләрдә дөньяви белем белән беррәттән дин мәдәнияте һәм этика дәресләре укытыла башлады. Минемчә, әлеге фәннең мәктәп программасына кертелүе - бүгенге заман таләбе. Балаларда башлангыч сыйныфтан ук инде төрле диннәр турында гомуми дөрес күзаллаулар булырга тиеш.

Әлеге дәресләрнең төп максаты - дөньяда булган диннәр белән танышу, аларның йолаларына һәм гореф-гадәтләренә карата үзара хөрмәт хисе тәрбияләү, төрле милләт кешеләре белән дус, тату, аңлашып яшәү.

Мин авыл укытучысы. Сыйныфымда укучылар арасында рус, керәшен, татар, чуаш балалары бар. Аларга гаиләдә дүрт төрле дини караш тәрбияләнә: бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре һәрберсенең үзгә. Толерантлыкны саклау максатыннан алар белән даими шөгыль сәгатьләре уздырам. Татарларның Гает бәйрәмендә коймак белән сыйланабыз, ә менә христианнарның Пасха бәйрәменә төрле төскә йомыркалар буядык. Әти-әниләр катнашында дини уен-викториналар уздыру да зур әһәмияткә ия. Балалар гаиләдән читкә киткәч “карурманда” калмас өчен традицион дин тамырларын өйрәнү бик кирәк, чөнки төрле секта-оешмалар ышанучан балаларыбызны адаштырырга атлыгып кына торалар. Андый “вербовщиклар” кулына эләккән баланы йолып алып калып булмый шул инде: ул толерант динне күрә алмаучы, бер яклы гына уйлаучы “зомби”га әйләнә дә куя.

Дин (чын дин турында сүз бара) кешене начарлыкка, сугышка өндәми. Ул чисталык, намуслылылык, әдәплелелек яклы. Һәр өммәткә иңдерелгән Изге китап буенча яшәгән кешеләр бер-берсе арасында фетнә чыгармас. Хәзерге буын шуны белеп үссә, илебездә толерантлык сакланып, халкыбыз элеккечә дус, тату яшәр иде дип уйлыйм.

# Р. ФӘХРЕДДИН ХЕЗМӘТЛӘРЕ – МИЛЛИ ТӘРБИЯ БИРҮНЕҢ НИГЕЗЕ

**Маслахова Рәсимә Минсагировна,**
**Закирова Гөлназ Рафиковна,**
**Әлмәт муниципаль районы**
**Кичүчат гомуми урта белем бирү мәктәбе**

“Россия Федерациясендә мәгариф турында” 273 нче федераль законның 2 нче маддәсендә: “Белем бирү – бердәм максатка юнәлтелгән укыту һәм тәрбия бирү процессы…” диелгән. Шунлыктан мәктәбебездә укыту һәм тәрбия бирү һәркайсы аерым-аерым түгел, бердәм белем бирү процессы буларак оештырылырга тиеш. Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандартлары шуны таләп итә.

Яшь буынга заманча тәрбия бирүдә иң мөһим юнәлешләрнең берсе – рухи-әхлакый тәрбия бирү дип уйлыйбыз. Бүгенге көн мәгарифе үз алдына белем һәм тәрбия бирүне, милли традицияләргә таянып, халык педагогикасы нигезендә алып бару бурычын куя.

Халык педагогикасы – зур акыл, сәламәт әхлак чишмәсе. Аның нигезендә кешелеклелек, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, гаделлек, тыйнаклык кебек матур сыйфатлар тәрбияләү ята. Шул ук вакытта, буыннардан буыннарга күчеп килә торган тәрбия чаралары искиткеч күптөрле.

Безнең Әлмәт муниципаль районы Кичүчат гомуми урта белем бирү мәктәбендә балаларны халык педагогикасы, милли тәҗрибәләргә таянып, ислам белгече, фәлсәфәче, педагог, тарихчы, атаклы “Шура” журналының мөхәррире, галим, үз чорының үрнәк казые, киң карашлы җәмәгать эшлеклесе, татар халкының аксакалы булган Ризаэддин Фәхреддин мирасы аша тәрбияләүгә зур урын бирелә. Милләтебезнең зыялысы булган татар халкының күренекле мәгърифәтчесе мирасын өйрәтү һәм укыту – тәрбия

эшчәнлегендә куллану – мәктәптә системага салынган.

Бүгенге көндә мәктәпнең төп максаты: зыялы, югары культуралы, актив тормыш позициясенә ия булган укучы шәхесе тәрбияләү. Шул уңайдан татар теле һәм әдәбияты укытучылары, сыйныф җитәкчеләребез тарафыннан күпкырлы эш башкарыла. Тәрбия процессы, беренче чиратта, әти-әниләрдән башлана. Безнең укучыларыбызның әти-әниләре гомуми, сыйныф җыелышларына теләп йөриләр, Р.Фәхреддин хезмәтләренә нигезләнгән педагогик докладлар тыңлыйлар, анкеталар тутыралар, үзләре дә тәҗрибәләре белән уртаклашалар, ачык сыйныф сәгатьләрендә катнашалар, Ризаэддин Фәхреддин мемориаль музеенда үтүче һәрбер чарадан читтә калмыйлар. Районда рухи-әхлакый кыйммәтләр тәрбияләүгә багышланган “Балаларга әхлак тәрбиясе бирү – заман таләбе” дип исемләнгән республикакүләм ата-аналар конференциясендә дә балаларын Р.Фәхреддин хезмәтләре нигезендә тәрбияләүче дистәдән артык әниебез катнашты. ТР баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевның чыгышыннан әниләребез рухланып кайтты. Үз фикерләре белән мәктәп ата-аналар җыелышында бик теләп чыгыш ясадылар.

Р.Фәхреддин музеенда дистә елга якын “Музей түгәрәге” эшләп килә. Түгәрәк әгъзалары, нигездә, – башлангыч сыйныф укучылары. Музей җитәкчесе Гимранова Диләрә Габделкавиевна Риза Фәхреддиннең “Бала чакта алган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас” дигән сүзләренә нигезләнеп эшли. Ел дәвамында музейга экскурсияләр оештыру традициягә кергән. Һәр елны гыйнвар аенда, Р.Фәхреддиннең туган көне уңаеннан, мәктәптә “Фәхреддин айлыгы” уздырыла. Яшь буынга ныклы тәрбия һәм белем бирүне күз алдында тотып, мәктәптә «Риза Фахреддиннең варислары» дигән балалар оешмасы да актив эшләп килә “Без – Фәхреддин варислары” исеме астында фәнни-тикшерү эшләре буенча эзләнүләр, викториналар, галим

тормышы һәм иҗаты буенча бәйгеләр, ачык дәресләр, сыйныф һәм тәрбия сәгатьләре үткәрелә. Район, республика һәм бөтенрәсәй күләмендә уздырыла торган чараларда укучыларыбыз актив катнашалар. Мәсәлән: Р. Фәхреддин иҗатына багышланган презентацияләр конкурсында һәм Р. Фәхреддиннең 155 еллыгына багышланган “Галимне беләсеңме?” бәйгесендә 2нче урыннарны яулап, II дәрәҗә диплом, грамота һәм кыйммәтле бүләкләргә лаек булдык.

Авылыбызның йөзек кашы – аның чишмәләре. Ә һәр чишмәнең үз моңы, үз догасы бар. Табигать үзе тудырган, халык олылап Ризаэддин Фәхреддин исеме белән атаган чишмә дә Кичүчат авылының горурлыгы. Бу чишмә – “Экологик сукмак ” тукталышының әһәмиятле бер өлеше.

2010 нчы елның 18 нче июнендә “Регион тормышында музей” исемле республика фәнни-практик конференциясе вәкилләрен укучыларыбыз сәламләделәр, ә килгән кунаклар Р.Фәхреддиннең мемориаль музее һәм Т.Миннебаевның әдәби-туган як музее турында мәгълүмат алдылар. 2010 нчы елның июлендә Бөтенрәсәй татар теле һәм әдәбияты укытучыларының квалификациясен күтәрү курслары рамкасында “Федераль дәүләт белем стандартларын кабул итү шартларында дәвамлылык принцибы” дигән темага багышланган Бөтенроссия семинары булды.

Кичүчат авылы җирлегендә һәр елны “Туганнарның кадерен белик” дип аталган очрашу үтә. Бу чара Р.Фәхреддин туганнарын барлап кына калмый, музей фондын арттыруда да зур роль уйный.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Маслахова Р.М. мәктәбебездә икенче ел “Әхлак дәресләре” алып бара. “Әдәп-әхлак дәресләре” программасы дәүләт документларына нигезләнеп, фәнни-методик, гамәли һәм эзлекле рәвештә язылган аңлатма язуыннан, программаның максатлары һәм бурычларыннан, төп программаның тематикасыннан һәм эчтәлегеннән, календарь-тематик планлаштырудан

һәм кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

Әдәплелек дәресләре милли тарихыбызга, милли гөреф гадәтләребезгә, үткәнебезгә, авылдашыбыз Р.Фәхреддин хезмәтләренә нигезләнеп алып барыла. Укытучыбызның тәҗрибәсен өйрәнергә Республикабызның башка мәктәпләреннән дә килделәр. Маслахованың дәресләре дин, җәмәгать эшлеклеләре тарафыннан да югары бәяләнде. Ул төзегән авторлык программасына нигезләнеп районыбызның күп мәктәпләрендә әхлак дәресләре алып барыла.

“Әдәп-әхлак дәресләре” кысаларында 2013 нче елның 27нче ноябрендә мәктәбебездә “Җәннәт аналарның аяк астында” дип исемләнгән конференция үткәрелде. Конференциядә өлкән сыйныф укучылары, күп балалы әниләр, укытучылар, Р.Фәхреддин мемориаль музей җитәкчесе Гимранова Д.К., Әлмәт муниципаль институтының уку эшләре буенча проректор, ф.ф.к., доцент Шаһиев Р.Ш. катнашты. Әлмәт шәһәре һәм районы имаммөхтәсибе Фәһим хәзрәт, ТР баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев укучыларга үзләренең нәсыйхәтләрен җиткерделәр. Конференция татар теле һәм әдәбияты куйган максатларны күздә тотып оештырылды. Әниләргә багышланган чара бай эчтәлекле, уйланылган: Ана турында шигырьләр, җырлар яңгырады, әниләргә багышлап язылган иншалар укылды. Балаларның барлык чыгышлары да әдәби әсәрләр белән тыгыз бәйләнештә барды.

2014 нче елның 17 нче гыйнварында Кичүчат гомуми урта мәктәбендә “Р.Фәхреддин – “Шура” журналы мөхәррире” исеме астында ТР журналистлары белән очрашу узды. Бу чара Р.Фәхреддиннең 155-еллыгына багышланган иде. Чарада “Әдәп-әхлак дәресләре” әгъзалары да чыгыш ясады.

2014 нче елның 14 нче маенда мәктәбебездә “Дин һәм тәрбия” исеме астында республикакүләм семинар булып узды. Чарада югары дәрәҗәдәге вәкилләр катнашты.

Семинарда “Ислам дине һәм медицина замана афәтләренә каршы” һәм күренекле татар мәгърифәтчесе Мифтахетдин Акмулланың “Иң әвәле кирәк нәрсә иман, дигән” әсәренә нигезләнгән “Әхлакый кыйммәтләр” исемле дәресләр күрсәтелде. Укытучылар дәресләрдә кешеләр арасындагы мөнәсәбәт, бу тормышта уңышка ирешү, җәмгыятьтә үз урыныңны табу юлында әхлак тәрбиясенең роле, аларның кыйммәтен ассызыклады.

Һәр елны мәктәбебездә хезмәт һәм ял , мәктәп яны лагерьләре эшләп килә. Үткән елда шулар белән беррәттән август аенда Республикакүләм “Сәләт” лагере эшчәнлеге дә укучылар күңелендә тирән эз калдырды. “Сәләт” лагере эшчәнлегенең төп максаты – бөтен дөнья халкына танылган, исеме тарих битләренә язылган, хезмәтләре халык күңелендә лаеклы урын алган татар мәгърифәтчеләренең берсен дөньяга бүләк иткән Кичүчат авылы белән таныштыру, Р.Фәхреддин хезмәтләрен өйрәнү һәм тормышта кулланугa этәреш бирү.

Мәктәбебездә Мәдәният елы кысаларында 2014нче елның 22нче октябрендә “Дин һәм тәрбия” темасына багышланган республикакүләм семинар узды. Ул “Тәрбия – балаларны гүзәл холык белән холыкландыру, һөнәр һәм мәгърифәткә өндәү, укырга һәм язарга өйрәтүдән гыйбарәт булыр” дигән девиз астында үтте. Семинарда Маслахова Р.М. җитәкчелегендә 6нчы сыйныф укучылары “Кешенең иң олы байлыгы – акыл, гыйлем һәм әдәплелек” темасы астында әхлакый тәрбия бирүгә нигезләнгән дәрес күрсәттеләр. Дәрес Р.Фәхреддиннең “Нәсыйхәт” китабында урнаштырылган “Шәкертлек әдәпләре” басмасының “Гыйлем” бүлегенә нигезләнеп үткәрелде. Җәлил хәзрәт укучылар белән әхлакый кыйммәтләребез турында түгәрәк өстәл артында сөйләшү үткәрде.

21 нче ноябрь көнне Россиядә һәм Татарстан җөмһүриятендә Мәдәният елы, Р. Фәхреддиннең тууына

155 ел тулу уңаеннан оештырылган “Р. Фәхреддин: рухият, мәдәният, мәгърифәт” I Бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференциясе дә Кичүчат урта мәктәбе базасында үткәрелде. Конференция эшчәнлегендә укытучылар, укучылар актив катнашты. Закирова Г.Р., Салахова Г.О., Хусаинова С.Ә. лар “Без – Фәхреддин оныклары”, Фарукшина Р.Р., Загирова Н.С. “Чишмәләр иле син, туган як”, Талипова Н.М. “Акбүз атым-ак канатым”, Рамазанова Л.Ә. “Р.Фәхреддин туган ягына виртуаль сәяхәт”, Сабитова Р.Х., Исхакова Р.Ш. “Филология фәннәре кандидаты Тәлгать Миннебаев исемендәге мәктәп музеена сәяхәт” дип исемләнгән мастер-класслар үткәрделәр. Маслахова Р.М. әдәп-әхлак дәресләре күрсәтте. Бөек мәгърифәтчебез халык традицияләрен, культурасын саклау һәм үстерү, яңа буынга тапшыруга зур әһәмият биргән. «Һәр милләт кешесе үзенең үткәнен белсен һәм үз тарихы белән дус булсын», – ди Р.Фәхреддин. Мәктәптә шул уңайдан укучылар белән «Шәҗәрә – тәрбиянең асыл ташы» дигән баш астында гаилә шәҗәрәләрен төзү буенча киң эш җәелдерелде. Бик күп укучы үзенең нәсел агачын төзеде һәм туганнары белән тагын да тыгызрак элемтәләр урнаштырды. Рус теле һәм әдәбияты уытучысы Маннапова Х.К. әлеге теманы яктыртып, Рәсәй кунаклары өчен мастер-класс күрсәтте.

Һәр дәрес милли байлыгыбызга, Р.Фәхреддин хезмәтләренә, тәҗрибәбезгә нигезләнеп балаларга әдәп-әхлак тәрбиясе, туган ягы белән горурлану, ярату хисе тәрбияләүгә юнәлтелгән иде. Насыбуллина Л.М. “Үзең белгәнне кешеләргә дә өйрәт” диеп исемләнгән кул эшләре, Арипова Г.И. “Квиллинг” остаханәсе эшен бик оста итеп оештырдылар. Остаханәдә әниләрнең дә катнашуы бик отышлы булды. Укучыларыбыз һәм әти-әниләрнең кул эшләреннән күргәзмә оештырылды.

Безнең буынның өмете – киләчәк яшьләребез. Максат – татар яшьләренең тотрыклы, иманлы булуы. Бер-беребезгә

әдәпле, ихтирамлы, шәфкатьле булыйк, шул вакытта гына үзебезгә әдәпле, милли үзаңлы, яхшы алмашчылар әзерли алабыз. Мәкаләбезне Р.Фәхреддиннең васыять сүзләре белән тәгәллисе килә. “Кешеләр! Тормышның кадерен белегез! Кыйммәтле вакытыгызны бушка уздырмагыз. Сезне һәрвакытта яхшы сүз белән искә алсыннар дисәгез, аны үзегезнең динегезгә, сезне чолгап алган кешеләргә бүләк итегез... Намусыгыз чиста булсын!”

Халыкка, хакыйкатькә хезмәт итү, иманга тугрылык – яшәешнең асыл максаты. Р.Фәхреддин тормышын һәм хезмәтләрен өйрәнеп, үзебезгә ясаган нәтиҗәләрне киләчәктә хәерле юлда кулланырга насыйп булса иде.

**Әдәбият исемлеге:**


1. Гайнуллин М. Риза Фәхреддинов // Татар әдәбияты тарихы.6 томда.2 том. X1X йөз татар әдәбияты. – Казан: Тат. кит. нәшр.,1985.
2. Госманов Миркасыйм. Ризаэддин Фәхреддинов мирасы // Үткәннән киләчәккә: Фәнни-публицистик мәкаләләр. – Казан: Тат. кит. нәшр.,1990. – 51–72б.
3. Нәсыйхәт. Әхлак гыйлеменнән/Ризаэддин Фәхреддин. – Казан: Мәгариф, 2005. – 184б.
4. Рәхимкулова М. Р.Фәхреддиннең педагогик карашлары // Хәзинә. – 1999. – 21 гыйнвар.
5. Р. Фәхреддин. Фәнни-библиографик җыентык = Ризаэддин Фәхреддинов. Научно-библиографический сборник. – Казан: “Рухият” нәшр. – 1999. – 223б.
6. Шаһиев Рәфкать. Ризаэддин бине Фәхреддиннең тормыш юлы һәм иҗатди мирасы. Махсус курс программасы. – Әлмәт. – 2004.

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ БИРҮ

**Ганиева Рәзинә Салихҗан кызы,**
**ТР Апас муниципаль районы**
**Апас урта (тулы) гомуми белем бирү,**
**аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү мәктәбенең**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

Соңгы елларда бөтен кешене борчыган проблемаларның берсе – яшьләрне патриотик рухта тәрбияләүнең җитенкерәмәве.

Җәмгыятьнең мораль кризис кичерүе, әхлак нормаларының таркала баруы, “кеше кешегә дус һәм иптәш”, ”кеше горур яңгырый” гыйбарәләренең, игелек, мәрхәмәтлелек сыйфатларының кими баруы яшьләргә кире йогынты ясый.

Патриотик эш абстракт характерда була алмый. Ул югары идеяләр һәм рухи хисләр тәрбияләүне, ә бу, үз чиратында, гомум – милли идеология әзерләнүе һәм тормышка ашыруны таләп итә. Ватанга чын мәхәббәт – аның бүгенгесе һәм киләчәге, чәчәк атуы хакында даими кайгырту дигән сүз ул.

Яшьләрне патротик рухта тәрбияләү эше тулаем педагогика фәне кебек фәнни, системалы булырга тиеш.Аның югары идеяле булуы, өзлексез алып барылуы мөһим.

Яшьләр һәм укучылар арасында патриотик тәрбия эше алып баруда аларны сугышчан, хезмәт традицияләре, ватан тарихына хөрмәт белән карау рухында тәрбияләү мөһим урын алып тора. Яшьләрне патриотик рухта тәрбияләүдә төп рольне укытучы үти.Укытучы – ул буыннарны тоташтыручы, белем биреп кенә калмыйча ,укучыларга өлкән буыннарның рухи байлыгын җиткерүче дә.

Һәр дәрес, бигрәк тә тарих һәм әдәбият дәресләре, клас-

стан тыш чаралар патриотик тәрбия бирү мәктәбе булырга тиеш. Ватанга мәхәббәт әлифбадагы рәсемнәрдән ,мәктәп музеенда булудан,ветераннар белән очрашудан, аларның сугыш һәм хезмәт геройлары турында сөйләшүләреннән башлана.

Әдәбият һәм татар теле дәресләрендә патриотик тәрбия бирүгә зур игътибар бирергә тырышам. Мәсәлән, башкалабыз тарихын өйрәнгәндә башкалабызның тарихы, бүгенгесе белән таныштыру, укучыларда милли горурлык ,патриотик хисләр тәрбияләү максаты куела. Мин татар теле дәресләрендә әлеге максатка ирешү өчен, яңа материал аңлатканда, кара –каршы сөйләшүләр уздырганда, укучыларның белемнәрен тикшергәндә, Казан турында җөмләләр, текстлар файдаланам. Мәсәлән,7 класста “Тулы һәм ким җөмләләр” темасын өйрәнгәндә, дәрес башында белемнәрне актуальләштерү өчен “Борынгы Казан Болакның уң ягындагы биек урынга салына,” – дигән җөмләгә өлешчә синтаксик анализ ясатып, Болак буе турында тарихи вакыйгалар турында мәгълүмат бирелә. Алга таба, яңа тема материалын аңлатканда, балалар игътибарына диалог тәкъдим ителә:

– Муса Җәлилгә һәйкәл кайчан куелган?
– 1966 елда.
– Казан шәһәрендә нинди архитектура һәйкәлләре бар?
– Сөембикә манарасы, Кремль бинасы...

Беренчедән, укучыларга башкала тарихы белән бәйле яңа мәгълүматлар бирелә, икенчедән, әлеге җөмләләрне тикшерү барышында укучылар тулы һәм ким җөмләләрне аерырга өйрәнә.

Г.Кутуйның “Сагыну” нәсерен өйрәнгәндә дә укучыларга патриотик тәрбия бирергә мөмкин. Әсәрдә солдатның туган илен сагыну хисләре чагылдырыла. Туган ил һәркем өчен кадерле һәм якын. Шулай ук М.Җәлил, А.Алиш Ф.Кәрим иҗатларын өйрәнү дә укучыларга патриотик

тәрбия бирүдә матур үрнәк булып торалар.

Мәсәлән, 7 нче сыйныфта Фатих Кәрим иҗатын өйрәнүгә һәм анализлауга 2 сәгать, «Кыңгыраулы яшел гармун» поэмасын укып фикер алышуга 1 сәгать вакыт бирелә. Ул дәресләрдә аның «Ант», «Ватаным өчен», «Сөйләр сүзләр»дигән шигырьләр өйрәнелергә тиеш. Бу шигырьләр белән генә чикләнү – шагыйрьне үз Ватанына бирелгән чын патриот, ялкынлы гражданин икәнлеген тулысынча ачарга мөмкинлек бирми. Шуның өчен мин Ф.Кәрим иҗатына багышланган һәр дәресне өстәмә материаллар белән баетам.

Дәрес алдыннан үткәрелә торган орфографик биш минутлыкларда укучыларның сүзлек дәфтәренә 5-6 сүз (шрифт белән) яздырам һәм шунда ук тикшерәм. Ф.Кәрим иҗатына багышланган дәресләрдә: патриот, окоп, Ватан, немец, вөҗдан, рядовой, гомер һ.б сүзләрне язабыз. Аларның лексик мәгънәләрен аңлатам, шулар аша укучыларда патриотизм турында дөрес фикер формалаштырырга омтылам. Укучылар бу дәресләрдә 30-35 сүз язарга өйрәнәләр.

Ф.Кәрим иҗатын өйрәнүгә керешү алдыннан, һәр укучыга дифференциаль эш бирәм. Менә аларның кайберләре:

1. Фронтовик шагыйрь Ф.Кәримнең тормыш юлы – чын солдат юлы.
2. «Разведчик язмалары» әсәренең эчтәлеге.
3. «Язгы төндә» әсәренең төп геройларына характеристика.
4. Алексей Чхеидзеның «Записки Дунайского разведчика» әсәре буенча яшь эзтабарлар эшчәнлеге.
5. «Кыңгыраулы яшел гармун» әсәрендә солдатның кешелек сыйфатлары, ватанпәрвәрлек билгеләре.

Бу темалар буенча әдәбият күрсәтелә, укучыларның әзерлеге тикшерелә. Чыгышлары тыңлана, әзерлекләренә анализ ясала, кирәк булса, башка укучылар тулыландыра.

Ф.Кәрим шигырьләрен өйрәнгәндә, укытучының һәрбер шигырьне сәнгатьле итеп укуы, балаларның

эмоциясенә тәэсир итә алуы аеруча әһәмияткә ия. Үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Моның өчен һәр бала үз гаиләсенең тарихын белергә, шуның аша халык тарихына якынаерга тиеш. Гаяз Исхакыйның “Сөннәтче бабай” әсәре моңа ачык мисал булып тора. Бу әсәрдә үз милләтен сөюче, үз нәселен тугыз бабасына кадәр белүче бабай – сөннәтче образы бирелә. Шушы әсәрне өйрәнгәннән соң, нәсел шәҗәрәсе эшләтәм. Үз шәҗәрәләре турында сөйләгәндә,укучылар йөзендәге горурлык хисләрен күрми мөмкин түгел. Шәҗәрәне өйрәнү нәсел-ыру традицияләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, әдәп-әхлагын, шөгыль-кәсепләрен белү һәм дәвам иттерү өчен дә кирәк. Шулай булганда гына яшь кеше милләт җанлы, үз халкының улы булып җитлегә ала, анда милли аң ышанычлы формалаша.

Кыскасы, халкыбызның бай мирасы ярдәмендә үсеп килүче яшь буынның күңеленә изге орлыклар салу – тәрбия эшенең төп максаты.

Үз республикаң, районың, авылың, мәктәбең ирешкән уңышлар белән горурлана белү,аны тагын да алга җибәрү өчен үз тырышлыгыңны кую синең югары әхлаклы, үз илеңнең патриоты икәнеңне билгели.

Бүгенге көн патриоты ул җитештерүчән хезмәттә актив катнаша, үз тамагын үзе туйдыра ала, кемнәндер бәхет көтеп ятмый.

Безгә ата-аналар җилкәсен кимереп ятучы, төннәр буе музыка акыртып, эчеп-исереп, кешеләрнең тынычлыгын бозучы, кемнеңдер зур көч куеп җыйган мал-мөлкәтләрен урлаучы караклар, ялкаулар, җилкуарлар кирәкми. Андый кешеләр ил алдында торган катлаулы бурычларны хәл итә алмыйлар.

Патриот булу – иң элек үз халкың, үз илең өчен көчеңне кызганмыйча, армый-талмый бөтен энергияңне эшкә җигү, анын иминлеге турында һәрвакыт кайгыртып тору ул. Бүген Ватан бездән шуны таләп итә.

# МИНЕМ ГАИЛӘМ ТАРИХЫНДА – СУГЫШ

**Мәҗитова Рәмзия Габдрауфовна,
Саба районы Юлбат урта мәктәбенең
инглиз теле укытучысы**

Сугыш... Гаиләләрне төпсез кайгыга салган, балаларны картайткан, хатыннарны тол иткән, карт-корыны ял итеп утырыр урында ат урынына эшләткән сугыш... Илебездә сугыш ишек какмаган гаиләләр юктыр мөгаен.

Әйе, 1941-1945 нче елгы, бик зур корбаннар китергән дәһшәтле Бөек Ватан сугышы минем гаиләмне дә читләтеп узмаган. Минем әниемнең дүрт абыйсы сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китәләр. Әниемнең иң олы абыйсы Хаҗиев Хуҗа Хаҗиәхмәт улы, (1899-1984) 1942 нче елның 25 нче февралендә сугышка алына. Калинин, Белоруссия фронтларында 1259 һәм 245 нче укчы полк составында укчы булып катнаша. “Сугышчан хезмәтләре өчен”, “Германияне җиңгән өчен” медальләре белән бүләкләнә.

Әниемнең икенче абыйсы, Хаҗиев Баймөхәммәт Хаҗиәхмәт улы, (1901-1975) хәрби кеше була. Сугышка 1941нче елның беренче көнендә үк китә. Беренче Белоруссия фронтында Рокоссовский армиясендә батальон командиры булып сугышның ахырына кадәр барып җитә. Сугышны 9 Май көнне Чехославакиянең Жамберк шәһәрендә тәмамлавын, “Руда Армаде! Наздар! Наздар!” дип чехларның безнең гаскәрләрне сәламләвен, бик якшы кабул итүләрен хәтеренә ала торган була. Сугыштан исән – имин кайтуына гаҗәпләнә. “Нинди генә хәлләр күрмәдем... Командир гел алда була, югыйсә, ә миңа бер генә дә пуля тимәде, яраланмадым. Ходай саклагандыр инде” дип әйтә торган була ул. Ике Ватан сугышы ордены, ике Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнелә.

Әниемнең өченче абыйсы, Хаҗиев Таҗмөхәммәт

Хаҗиәхмәт улына (1908нче елгы) сугыштан исән-имин әйләнеп кайту насыйп булмый. Сугышка 1943 нче елда китә ул. Курск Дугасы өчен барган сугышларда катнашуы билгеле. "Днепрны исән-сау чыктык, ат тиресеннән аш пешерергә йөрибез..." дигән хаты аннан соңгы хәбәр була.

Әниемнең дүртенче абыйсы, Хаҗиев Миңлебай Хаҗиәхмәт улы (1916-1989), 1939-1940 нчы елгы Фин сугышыннан кайтып озак та үтми 1941 нче елның 6 июлендә Бөек Ватан сугышына китә. Төньяк фронтта хезмәт итә ул. Кандалакша, Петрозаводск, Мурманск шәһәрләрен дошман һөҗүменнән саклыйлар. Сержант, отделение командиры була.

Әтием, Габдрахманов Габдрәүф Габдрахман улы (1925-2004), 1943 нче елда 18 яше тулуга сугышка китә. Аны Ерак Көнчыгышка җибәрәләр. Сержант званиесе бирелә һәм отделение командиры итеп билгеләнелә. 255нче укчы дивизиянең 972 нче укчы полк составында японнарга каршы сугышта Сунгарь елгасы буенда катнаша."Германияне җиңгән өчен", "Японияне җиңгән өчен", "II дәрәҗә Ватан сугышы ордены" һәм башка медальләр белән бүләкләнелә. Туган якларга ул 1951нче елда гына әйләнеп кайта. 1955-1968 нче елларда Мәртен, Сатыш мәктәбендә директор һәм лаеклы ялга чыкканчы тарих укытучысы булып эшли. "Мәгариф отличнигы" дигән исемгә лаек була. Җиңүнең 55 еллыгына аңа майор званиесе бирелә.

Иремнең бабасы, Мотыйков Мәҗит, сугыш кырларында хәбәрсез югала. Ә тагын бер бабасы, Фәрхуллин Фәрхетдин, сугышта алган яралардан соң озак яши алмый.

Фронтта дошманга каршы корал тотып сугышкан бабайлар белән рәттән тылда яшәүчеләр дә Җиңү көнен якынайта.

Әнием, Хаҗиева Рәшидә Хаҗиәхмәт кызы (1923-1993), 1940 нчы елда Казанда немец теле укытучылары хәзерли торган курсларны тәмамлый. Башта Әгерҗе районы Көек авылында укыта, сугыш башлангач үз ягына Саба районына кайта. "Балаларның өсләре кырык ямаулы, ачлы-туклы. Әммә

дәресләр бара. Ни дәфтәр, ни дәреслек, ни язу карасы юк. Ни туры килсә шунда язабыз, бер карандашны 3-4 кә бүләбез" дип сөйли торган була ул.

Таҗи абыйның хатыны, Фатыйма апа тракторда эшләгән. Бер басудан икенче басуга кадәр җәяү барганнар, запчастьләрне Шәмәрдәннән, Арчадан күтәреп ташыганнар. Әниемнең апалары Хөсникамал, Мәймүнә, иремнең әбиләре – Әминә, Хәтирә әбиләргә төрле авыр эшләрдә эшләргә туры килә. Урман кисәләр, окоп казыйлар, Шәмәрдәнгә икмәк ташыйлар...

Әтисе сугышка киткәндә 6 яшьлек булып калган Җофар бабай кычыткан, өшегән бәрәңге, алабута ашаулары́н, "уфалла" тартып өйләренә ягарга утын алып кайтуларын әле дә булса дулкынланып сөйли.

Әнә шулай картларга, хатын-кызларга, балаларга сугыш чорының бөтен эшен, нужасын, ялангачлыгын күрергә туры килә.

Без хәзер бик матур вакытта яшибез. Бу матур, рәхәт тормышның нинди ҖИҢҮ бәрабәренә булганын без беркайчан онытырга тиеш түгел! Күгебез һәрвакыт аяз, тыныч, илебез имин булсын иде!

«Беркем дә, берни дә онытылмый» дигән гыйбарә безнең өчен әхлакый канунга, иҗтимагый тормыш-көнкүрештәге гамәлләребезне бәяләү калыбына әйләнсен. Үз гомерләре бәрабәренә кешелекне фашизм афәтеннән йолып калган сугыш шәһитләре турындагы якты истәлек йөрәкләребездә мәңге саклаы́ныр.

Бу фоторәсем безнең гаилә, нәсел өчен бик истәлекле. Ул 1941 елның 23 июнендә Сабада фронтка озатканда төшерелгән.



1 рәт: (сулдан уңга) Исламов Тимерхуҗа (әбиемнең апасының ире) Галимҗанова Камәрия (сугышта медсестра булган), Хаҗиев Таҗмөхәммәт (хәбәрсез югалган), әбием Хаҗиева Рәшидә (озак еллар Сатыш мәктәбендә немец теле укыткан), Хаҗиев Миңнебай.

2 рәт: (сулдан уңга) Ибаттов Миңнемулла, әбиемнең апалары Исламова Хөсникамал, Хаҗиева Фатыйма, Хаҗиева Мәймүнә, Фатихов Кәшиф.

# ТАМЧЫ ШОУ «МОҢЛЫ БЕР ҖЫР»

**Шәмсетдинова Ләйсән Тимергали кызы,**
**ТР Саба муниципаль районы “Сәләтле балалар өчен аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган урта гомуми белем мәктәп-интернаты” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең өстәмә белем бирү педагогы**

**Максат:** 1. Укучыларны фәнни-гамәли эш алымнарына, эзлекле фикерләргә, чыганаклардан иң әһәмиятле материалларны сайлап ала белергә өйрәтү.

2. Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында укучыларның белемнәрен баету.

3. Укучыларга М.Җәлил үрнәгендә гражданлык тәрбиясе һәм патриотик тәрбия бирү.

4. Телевидениядә узачак “Тамчы-шоу” тапшыруына әзерләнү.

Җиһазлау: мультимедиа проекторы, компьютер, китаплар күргәзмәсе, ватман, төрле төстәге маркерлар, бүләкләү өчен диплом һәм истәлекле бүләкләр.

**Кичә барышы**

– Хәерле көн, исәнмесез хөрмәтле укучылар, тамашачылар. Бүген без “Тамчы-шоу” интелектуаль күңел ачу тапшыруын уздырырга дип җыелдык.

Әйдәгез, командаларның үзләре белән танышып узыйк. Сүзне Сәләтле балалар мәктәбенең 8 нче сыйныф укучыларыннан оешкан “Сәләтле йолдызлар” командасына бирәм. “Сәләтле йолдызлар” алга.

– 8 сыйныф укучыларына каршы чыгарга җөрьәт иттеләр шушы ук мәктәпнең 7 нче сыйныф укучыларының “Хыял” командасы. Сүз сезгә.

– Тагын бер команда – жюри әһелләре белән танышырбыз. (жюри әһелләре белән таныштыру)

– Аудиториядә бүгенге командаларның җанатарлары һәм мөгаллимнәре утыра. Шушындыйрак состав белән без башлап җибәрәбез һәм “Тамчы-шоу” интектуаль уенының I туры башланып китүен хәбәр итәбез.

– Кызлар – егетләр, I турда сезнең белән аралашуның төп темасы итеп безгә “Җәлил исеме белән” дигән тема әзерләнеп куелган иде. Мин беләм, сез Муса Җәлилнең тормыш юлы, иҗаты белән азмы-күпме хәбәрдәр булып әзерләнеп килергә тиеш идегез. Әлеге әзерлекнең дәрәҗәсен хәзер без сезнең белән тикшерербез. Сорауларга җавапларны күрсәтмә такталарга язып, соңыннан тулы җөмләләр белән сөйләп күрсәтергә тиеш буласыз. Сез әзерме? Кызлар-егетләр әзер, I турның беренче соравын яңгыратам.

1. Шагыйрьгә һәйкәл куелган мәйдан. (Беренче Май мәйданы).

2. Аның исемен йөртүче театр (Опера һәм балет театры).

3. Җәлилнең беренче китабы (“Барабыз”).

4. Беренче шигыренең исеме (“Бәхет”).

5. Җәлилнең туган авылы (Мостафа).

6. Ул әсирлеккә ничәнче елда эләгә (1942 елда).

7. “Хөкем алдыннан” картинасының авторы (Х. Якупов).

8. Мусаның әсирлектәге фамилиясе (Гомәров).

9. Шагыйрь портретын таштан иҗат итүче скульптор (Бакый Урманче).

10. Сугышка җибәрүне сорап язылган гаризалар саны (җиде).

– Командалар белән эшне төгәлләп торабыз, эшчәнлекне жюрига тапшырам. Рәхим итегез(жюри сүзе).

Кызлар-егетләр, без сезнең белән II турны башлыйбыз. Төп эшчәнлек экран белән бәйле булачак. Экран сезгә рәсемнәр тәкъдим итәчәк. Рәсемнәрдән соң сорау яңгырар. Мөмкин кадәр игътибарлырак булыгыз.







Сорау: Ничәнче рәсемдә Муса Җәлил күрсәтелде?

– Менә шушындый җаваплар ишеттек без II турда, нәтиҗәләр ясар өчен сүзне жюрига бирәбез.

– Без III турга килеп җиткәнебезне сизмичә дә калдык. III тур, гадәттә, 1 сүз белән башланып китә. Ләкин бу сүзне, таралышкан хәрефләрне бергә җыю рәвешендә, оештырып бетерергә кирәк. Хәрефләрне җыю нәтиҗәсендә Муса Җәлилнең нинди шигырь исемнәре барлыкка килде?

Ч в у ә и л р е п а к х ш г а н т ә (“Чулпанга”, “Ирек”, “Вәхшәт”)

– Шушы сүзләрдән башка, шушы ук хәрефләрне

кулланып тагын күпме сүз төзи алырбыз икән? Сезгә ярты минут вакыт бирелә.

Сүзләр язылган кәгазьләрне жюрига тапшырабыз.

**Капитаннар ярышы.**

– Сәләтле балалар мәктәбенең 7 нче сыйныф укучылары оештырган “Хыял” командасының капитаны белән сөйләшәбез. Тормышта килеп туган сорауларга да “әйе”, “юк” дип кенә җавап бирсәк әйбәт булыр иде ул. Шуңа күрә IV турны бер яктан җиңел, икенче яктан авыр дип әйтеп була. Син әзерме?

1. Китап сүзе фигыль сүз төркеменә карый. Юк.
2. Христиан Андерсон әкиятләр язу остасы. Әйе.
3. Зур, дәү сүзләре синонимнар. Әйе.
4. Тәүлектә 25 сәгать. Юк.
5. Муса Җәлилнең тормыш иптәше Әминә ханым.Әйе.
6. Мостафа авылыннан ага торган елга Нит елгасы. Әйе.
7. Кояш иртән бата. Юк.
8. Кышын да, җәен дә яшел агач ул – чыршы. Әйе.
9. Кар – ул явым-төшем. Әйе.
10. Апрель – ул яз ае. Әйе.

– Хәзер көндәшең “Сәләтле йолдызлар” командасы капитаны җавапларын түземсезләнеп көтәргә генә кала.. Син әзерме?

1. Мең санында 4 ноль бар. Юк.
2. О сузык аваз. Әйе.
3. Баян музыка уен коралы. Әйе.
4. Кол Шәриф мәчете Кремль территориясендә урнашкан. Әйе.
5. Вертолет җир асты транспорты. Юк.
6. Муса Мөхәммәдия мәдрәсәсендә укыган. Юк.
7. Кышын агачлар үсүдән туктый. Әйе.
8. “Моабит дәфтәрләре” – шартлы исем. Әйе.

9. Атнада 8 көн. Юк.
10. Курай ул рус халык уен коралы. Юк.

– Гомуми нәтиҗә ясау өчен сүзне жюрига бирәбез.
– Шулай итеп тапшыруның бүгенге җиңүчеләрен дә игълан итәр вакыт килеп җитте. “Хыял” командасы афәрин! Икенче дәрәҗәдәге җиңүчеләр – “Сәләтле йолдызлар” командасы. “Сәләтле йолдызлар” сезгә дә алкышлар.
– Бик күңелле булды сезнең белән уйнау. Тормышта алган белемнәрегез ярдәмгә килсен. Сезнең белән саубуллашабыз.

## СЕЗНЕҢ ТОРМЫШ – ҮЗЕ БАТЫРЛЫК

**(Сыйныф сәгате)**

**Нажия Шиһапова,**
**Апас районы Сатламыш урта мәктәбенең**
**югары категорияле башлангыч сыйныф укытучысы**

**Максат:** Укучыларны әти-әниләре һәм әби-бабаларының, гомумән, авылдашларның Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән батырлыклары, тырыш хезмәте белән таныштыру; ветераннарга олы ихтирам һәм хөрмәт хисе тәрбияләү; сугыш афәтенең һәр кеше, һәр гаилә өчен фаҗига булуын төшендерү; тынычлык сөюче шәхес тәрбияләү; герой шәхесләр белән таныштыру; туган якка,туган илгә мәхәббәт, төбәгебезнең үткән һәм бүгенге тарихын балалар күңеленә сеңдерү. Тарихи үткәнгә ихтирам һәм сугыш чоры балаларына хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Компьютер, проектор, экран, презентация, Бөек Җиңүгә багышлап чыгарылган стенд, әдәби әсәрләр күргәзмәсе, сугыш һәм тыл ветераннары хакындагы альбомнар “Җиңү көне җиңел бирелмәде...”, “Бөек җиңүгә

70 ел!”, “1941-1945” дигән язулар һәм “Ватан-ана чакыра” рәсеме урын ала.

Кичәгә Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм сугыш чоры балалары кунак итеп чакырыла.

**Чараның барышы**

**Укытучының кереш сүзе**: Хәерле көн, хөрмәтле авылдашларыбыз-сугыш һәм хезмәт ветераннары, укучылар! Бүген без, Сезнең батырлыкларга яңадан бер кабат сокланыр, Сезгә дан һәм мәдхия җырлар, Сезнең түземлелегегез, сабырлыгыгыз алдында баш ияр өчен, бу залга җыелдык. Халкыбызның Нәкый Исәнбәт сүзләренә язылган “Илкәем”җыры сезгә музыкаль сәлам булып яңгырасын.

**Җыр.”Илкәем”**

**Укытучы.** 1941ел. 22 июнь.Таң атып килә. Гүзәл авыллар, шәһәрләр тыныч йокыда. Әниләренең җылы куенында тәмле төшләр күреп нәни сабыйлар изрәп йоклыйлар .Шул вакытта канга туймас фашист этләре безнең чикне бозып авылларны ,шәһәрләрне үлем утына тоталар. Бөек Ватан сугышы башлана. Зәңгәр күкне канлы корым каплый.

Аяусыз сугыш башлана.1941 елда башланып киткән Бөек Ватан сугышы тарихта аерым урын алып тора. Төрле революцияләр, интервенция, колхозлашу, Сталин репрессияләре белән тәмам йончыган, таланган, хәерчеләнгән совет халкын янә бер кат ныклыкка сыный ул, яшәү-яшәмәвебезне көн тәртибенә куя.

Илебезгә көчле һәм рәхимсез дошманга каршы торырга туры килә. Сугышның беренче көненнән үк дошманга каршы көрәшкә бөтен халык күтәрелә. Фронттагы сугышчыларга да, басып алынган җирләрдә дошманга каршы сугышкан партизаннар һәм подпольщикларга да, фронтны бөтен кирәк-ярак белән тәэмин итеп торган тыл хезмәтчәннәренә дә бик авырга туры килә.

**Җыр.»Солдатлар» (Р. Әхмәтҗанов сүз., Ф. Әхмәдиев көе.)**

**Укытучы.** Якташларыбыз да бер мең дүрт йөз унсигез көн һәм төн дәвамында киерелгән җәя шикелле дәһшәтле вакыйгалар һәм моңарчы күрелмәгән язмыш сынавы чолганышында калалар. Татарстан Республикасы Апас районыннан Ватан сагына, ут эченә 9112 кеше китә. Әмма күбесенә туган-үскән нигезләренә кире әйләнеп кайтырга насыйп булмый шул, алар Ватан азатлыгы, Европаны фашизм тырнагыннан коткару өчен изге яуда башларын салып, чит-ят җирләрдә мәңгелеккә ятып калалар. Әмма уртак Ватан капкасын шакыган афәт никадәр генә куркыныч булмасын, ул дәһшәтле көннәрдә шәһәр-авылларыбыз фронт ихтыяҗларын кайгыртып яши.

***Экранда видеофильмнан өзек күрсәтелә.***

**Укытучы.** Илебезнең миллионнарча ир-егетләре эш коралларын сугыш коралларына алыштырды. Хәтәр сугыш елларында ил иминлеген сакларга дип Татарстаннан да 560 меңнән артык кеше фронтка китте. Алар дошман белән батырларча көрәште. 100 меңнән артык якташыбыз орден һәм медальләр белән бүләкләнде. 200гә якын Татарстан батырлары Советлар Союзы герое исеменә лаек булды. Җирдә яшәвебез белән без алар алдында бурычлы. “Беркем дә онытылмады, бернәрсә дә онытылмас”.

**Җыр.»Солдатлар» (К. Булатова сүз., М. Минһаҗев көе.)**

**Укытучы**. Апас районы Карамасар авылыннан да фронтка 142 кеше китә, 86сы яу кырында мәңгелеккә ятып кала. Сугыштан барлыгы 56 кеше әйләнеп кайта. Ләкин елдан-ел ветераннарыбыз сафы да сирәгәя бара.Бу Җиңү зур корбаннар аша килде һәм менә 70 ел инде илебез халкы тыныч тормышта яши. Дүрт ел сугыш дәвамында халкыбыз тудырган зур батырлыклар һәм кичергән зур газаплар 70 ел буена да, 100 ел буена да онытырлык түгел! Фашизмны Җиңү бәйрәмен билгеләп үткән язгы матур көннәрдә без исә

ветераннарны хөрмәтлибез, һәлак булган батырларны ихтирам белән искә алабыз.

**Укучы**

Онытылмый беркем дә!
Онытылмый берни дә.
Бабайларның, әтиләрнең
Дан юлыннан атлыйбыз.
Өлкән буын батырлыгын
Йөрәкләрдә саклыйбыз!

**Укытучы**.Әйе, Бөек Ватан сугышы тәмамлануга быел 70 ел тула. Илебездә ел саен 9 май – Җиңү көнен билгеләп үтәбез. Ул көн бәйрәм генә түгел, истәлекләр һәм хатирәләр көне дә. Җиңү бәйрәмнәре тагын шаулап узар. Ләкин кешеләр йөрәгендә сугыш калдырган яра-җәрәхәтләр һаман да сыкрый әле. Йөрәк яраларыбыздан һаман да кан саркып тора. Сугыш афәтен башыннан кичергән кешеләр кабат сугыш булуын беркайчан да теләмәсләр. Шунлыктан илебез халыклары сугышка каршы. Кешелек дөньясы тарих сабакларын онытырга тиеш түгел.

Шушы сугышта катнашып, әйләнеп кайтучы 56 ветеранybызның – бары берсе генә – хәзерге вакытта безнең арада – Әхтәмова Тәнзилә Шәнгәрәй кызына без бик рәхмәтле. Хөрмәтле ветераныбыз бүген бездә кунакта. Хәзер, укучылар, сүзне аңа бирик әле. Сугышның ачысын-төчесен татыган ветераныбызның инде чәчләренә ак бәсләр кунган. Сугыш аның күңелендә һич төзәлмәслек тирән яра, хатирә калдырган.

Әхтәмова Тәнзилә әби чыгышы. Миңа нибары 17 яшь иде. Без Чирмешән, Багыш авылларында окоп казу эшендә катнаштык. Көннәр искиткеч салкын. Окоп казудан кайткач Ульянково авылына дзот казырга җибәрәләр, апрель аенда гына авылга кайттым. Сугыш Мәскәүгә якынлашканда кызларны да алырга дигән приказ чыга. 1942 елда армиягә китәргә ризалыгымны бирдем, товар поездына утыртып алып

киттеләр. Мине Мәскәү оборонасын сакларга куйдылар. Мәскәү читләренең тирәләрен немецлар шартлаткан, тирә-як җимерелгән. Каты сугыш бара. Безнең бурыч: Мәскәүне немец самолётларыннан саклау, самолётның тавышыннан ук аерып хәбәр итә идек. Ләкин никадәр авыр булса да сыгылмадык, зарланмадык. “За оборону Москвы”,”Медаль Жукова”, Медаль “Отечественная Война” дигән медальләр белән бүләкләндем. Георгий Жуковның медальне үзе тапшыруы минем күңелемдә хәзер дә истә әле. Балалар, сезгә сугышны күрергә язмасын иде, ходай тәгалә андый авырлыкларны, күз яшьләрен күрсәтмәсен, киләчәк буыннар да ата-ана тигезлеге белән, озын-озак яшәп бәхетле булсыннар, дөньялар тыныч булсын!

**Укытучы.** Рәхмәт Сезгә бик зур**.** Олы ихтирамга лаеклы ветеранныбыз ул безнең Тәнзилә әби! Бүгенге көндә ул балаларының таянычы, оныкларының юанычы, олы йөрәкле, саф күңелле әүлия зат – Акъәби.

**Укытучы**. Шәһәрдә һәм авыл җирендә бары картлар, хатын-кызлар һәм балалар гына кала. Бөтен авырлыкларны җиңеп алар “Барысы да фронт өчен, барысы да Җиңү өчен” дигән лозунг астында эшлиләр. Промышленность оешмалары һәм колхоз-совхозлар хәрби шартларда эшләүгә күчерелә.Завод эшчеләре граната корпуслары, шартлаткычлар өчен аерым детальләр эшлиләр.Эш сәгате 18әр, хәтта 20шәр сәгатькә сузыла. Беркем дә авырсынмый, беркем дә сыкранмый.

Экранда: “Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!” язуы һәм сугыш картиналары күрсәтелә.

Бию (Смуглянка)

Сугыш фактларда:

1 укучы: Сугыш чоры үсмерләре... Сугыш башланганда аларга 17-20 яшь иде. Шушы 17-20 яшьлекләрнең 100дән 97се генә кире әйләнеп кайта алды. 100дән 97се! Онытмагыз бу санны!

2 укучы: Сугыш... Бу – 1725 җимерелгән һәм яндырылган шәһәр һәм поселок, 70 меңнән артык авыл. Сугыш – 32 мең җимерелгән завод-фабрика, юкка чыккан 65 мең километр тимер юл.

3 укучы: Сугыш – 900 көнгә сузылган Ленинград блокадасы. Көнгә 125 грамм икмәк... һәм тыныч халык өстенә яуган тонналаган бомба һәм снарядлар.

4 укучы: Сугыш... Брест крепостеннан Мәскәүгә кадәр чигенү юлы – 1000 километр, җиңү юлы – Мәскәү – Берлин – 1600 км. Туп-туры очсаң, самолет белән 4 сәгатьлек ара. Ә үрмәләп, бер күтәрелеп, бер чигенеп, бер егылып, бер торып, үлем белән якалаша-якалаша үтелгән бу юл 4 елга, 1418 көнгә сузыла.

5 укучы: Сугыш – 1943 елның 22 мартында белорусь авылы Хатыньда терелэй яндырылган 149 кеше. Аларның 75 е балалар, иң кечкенәсенә 7 атна! Фашизмның яшәргә хакы юклыкка бары бер мисал бу!

6 укучы: Сугыш – көнгә 20шәр сәгать завод станоклары артында басып тору. Сугыш – авыл кешеләренең тозлы тирендә үскән икмәк, үгез җигеп сука сукалау, куллар канаганчы урак уру, көлтә бәйләү...

Укытучы .Сугыш чоры балалары... Аларның да инде иң-иң кечкенәсенә 65-70 яшь. Вакыт аяусыз. Җиңү көнен якынайткан ветераннарыбыз әкрен-әкрен арабыздан китеп баралар. Саклыйсы, кадерлисе иде аларны! Шулай ук бүген бездә кунакта сугыш чоры баласы – җиңүгә үзеннән зур өлеш керткән ветераннарыбызның берсе – Гыйльманова Миңсара әби. Хәзер сүзне аңа бирик әле.

Гыйльманова Миңсара әби чыгышы. 1940 елның декабрендә безне, Карамасардан берничә кызны, вербовка белән Свердловск өлкәсенең Серов шәһәренә эшкә җибәрделәр.Ул да түгел сугыш башланып китте. Сугыш чорында 76 нчы номерлы, хәрби механик заводта 16 килограммлы снарядлар җитештердек. Әлеге заводта 4 ел буе

эшләдем.Туган авылыма 1944 елның июнендә генә кайттым. Аннары колхозда байтак вакытлар бригадирлык иттем.

Укытучы. Рәхмәт Сезгә бик зур. Шулай ук олы ихтирамга лаеклы ветеранproblemsыбыз ул безнең Миңсара әби! Бүгенге көндә ул балаларының таянычы, оныкларының юанычы, олы йөрәкле, саф күңелле әүлия зат – Акъәби.

Экранда тыл батырлары турындагы рәсемнәр.

Укытучы. Ирләре, уллары, туганнары зур батырлыклар күрсәткәндә, тылдагы хатын-кызларыбыз үзләрен аямыйча эшлиләр. Тылдагы хатын-кызларның батырлыгы сугыш кырында туган батырлыкка тиң. Әйе, авылда картлар, хатын-кызлар һәм балалар гына кала. Ә тормышны алып барырга кирәк иде-игенен дә игәргә, балаларны да ачялангач итмәскә, сугышка төрле җылы киемнәр дә әзерләп җибәрергә, гомер буе бетмәс төсле тоелган налогын да илтеп түләргә кирәк булган. Ләкин алар сынатмаганнар, сыгылмаганнар. Бөтен булган физик авырлыкларга түзәр идең әле, авылларга кара пичәтле кәгазьләр агыла. Алма кебек хатыннар балаларын кочаклап ирсез, сабыйлар әтисез, җиләк кебек кызлар ярсыз калалар. Шушы сугыш вакытында тол калган һәм хәзерге вакытка кадәр исән-сау булып яңа гына гүр иясе булган әбиләребез: Әминова Сәкинә, Гайнуллина Мәүҗүдә, Шәяхмәтова Сәүдә әбиләр. Еллар картайтса да аларның йөрәкләре, күңелләре яшь, яшәү дәртләре сүнмәгән иде әле. Аларның тормыш юллары-без яшьләр өчен дә батырлыкка тиң. 103 яшьлек Карамасарның Акъәбие Мәүҗүдә әби Гайнуллина икенче гасырлык гомеренә аяк баскан иде. Моны бәхет, язмыш дими ни диярсең.

Оныгы Айнурның дәү әбисе – Мәүҗүдә әби турында язган иншасын тыңлау.

**Тол әбиләрнең фотосурәтләре.**

**Укытучы.** Сугыш беткәч тә, тыл каһарманнары төнне көнгә, көнне төнгә ялгап эшләүләрен дәвам итәләр, чөнки илдәге сугыш китергән хәрабәләрне торгызырга кирәк. Алар

тагын ил язмышына кушылып хезмәткә җигеләләр. Алар арасында хәзерге көнгә кадәр намус белән үз хезмәтләрен башкаручылар байтак. Күпләре инде гаиләдә олы ихтирамлы кешеләр,балаларының таянычы, оныкларының юанычы. Алар әле дә олы йөрәкле, нык бәдәнле,саф күңелле әүлия затлар,сугыш чоры кешеләре!

**Укучылар**:
Сабый гына идек ул елларда,
Җирләр сөреп, иген икмәдек.
Әткәйләрне сагынып елый-елый
Чүп утадык, башак чүпләдек.
Торып “кояш белән” көянтәләп
Су ташыдык тракторларга.
Йотып ачлык хисен, юандык без,
Тургай моңын тыңлап кырларда.

Тулпар атлар киткәч яу кырына
Үгез-тана керде тәртәгә.
Күпме малай үгез “дулавыннан”
Үксегәндер язгы иртәдә?!

Әниләр, әбиләр, без- үсмерләр
Урак урдык, бергә ярышып.
Истәлеккә кәкре урак эзе
Бармакларда калды ябышып.

Урган учмалардан көлтә бәйләп,
Сосланнарны бик күп тездек без.
Көнне төнгә ялгап, кырда эшләп,
Якынайттык җиңү көнен без.

5.Күзләремә тирән эзен салган
Сугыш елларының шәүләсе.

Мәңгелеккә шаһит булып калды
Ятимлекнең кара пәрдәсе...
6.Йөзләремә сарылып, сеңеп калган
Үткән авыр еллар сулышы.
Төшләремә кереп эзәрлекли
Аерылуның ачы сагышы.

7.Йөрәгемне авыр яралады
Язмыш сынаулары ул чакта
Сагыш- моңнар, кайгы- хәсрәтләрем
Юлдаш булды миңа һәрчакта...

8.Күңелемдә яши төер булып
Сугыш йоткан авыр балачак.
Күзләремә кунган моңсу караш
Гомерем буе озата барачак.

**Укытучы.** Батырлык ул – рухи матурлык .Әнә шуңа күрә дә халкыбыз кеше күңеленең рухи бөклеген югары бәяләгән. Әйе батырлар исеме үлемсез. Якташыбыз, авылдашыбыз фронтовик шагыйрь Гали Хуҗиевны да бүген искә алмый мөмкин түгел, укучылар. Ул белгәнебезчә Апас районы Карамасар авылында туып үскән. Бөек Ватан сугышы фронтында, хәрәкәттәге армия сафларында 1942 елдан 1946 елга кадәр Польшада, Германиядә, Чехословакиядә, Австриядә була. Хәрби дәрәҗәсе-капитан. Кызыл Йолдыз һәм өч медаль белән бүләкләнә.Сугыштан соң да, аңа кадәр дә без – укучылар өчен зур хезмәт куя, иҗат итә. Бүгенге көндә авылыбызның бер урамы аның исемен йөртә, мәктәбебездә аның иҗаты, китаплары тупланган кечкенә генә “музей” да эшләп килә. Әйе, батырларның кылган изге гамәлләре, данлы исемнәре әкиятләргә күчкән, җыр-дастаннарга кергән. Каһарманлык, чорлар аша кичеп, бүгенге көннәргә килеп җиткән. Халкыбыз улларының

һәм кызларының Бөек Ватан сугышы чорында күрсәткән тиңдәшсез фидакарьлеге дә күңелләрдән мәңге җуелмас. Шул олуг Батырлык алдында безнең дәвер кешеләре генә түгел, киләсе гасырларда яшәүчеләр дә башларын иярләр әле. Хәзер укучылар, хөрмәтле ветераннарыбызга үзебез иҗат иткән шигырьләребезне сөйләп китик әле. Без дә кечкенә “шагыйьрләр бит әйеме?

**Укучы**. **“Сугыш булмасын!”**
Минем бабам сугыштан
Җиңүче булып кайткан.
Сугышкан дошманга каршы
Орденнар алып кайткан.
Без бит сугыш турында
Кинолардан күрәбез,
Я булмаса китаптан
Укып кына беләбез.
Сугыш уты беркайчан да
Булмасын ди бабайлар,
Күкләр аяз, көннәр тыныч
Һәммәгезгә, балалар! **(Зарипова Ильгина)**

**Укучы**
**“Матур булсын!”**
Сугыш уты илебезне
Чолгап алмасын башка
Саклыйк әле тынычлыкны,
Тынычлык бик кирәк бит!
Бу куркыныч сугыш газапларын
Ишетеп кенә беләбез.
Матур булсын иде тормышыбыз
Аяз булсын күгебез.
Әти-әни, әби-бабайларның
Кичергәнен кабат кичермик

Бу тынычлык, якты матур тормыш-
Барысы да без-балалар өчен бит!

**Укучы** Данлы бәйрәм -Бөек Җиңү көне белән Сезне, хөрмәтле ветераннар! Хәзер башкарылачак җырыбыз Сезгә бәйрәм бүләге булсын

**Җыр: "Матур булсын."**
**Укучы**.
Алыгыз Сез бүген бүләк итеп
Котлауларның иң зур бәйләмен
Каршылагыз тагын бик күп тапкыр
Якты Җиңү бәйрәмен!(**Чәчәкләр бүләк итү)**
Ал нурларга төренеп кояш байый
Үткән юллар килә күңелгә.
Җиңүләрне яулап алган көннәр
Онытылмаслар гомер-гомергә!

Җиңү килде җирне нурга күмеп.
Шатлык белән күзне чылатып.
Килде ул көн горур күкрәкләрдә.
Орден-медальләрне чыңлатып.

Картаймагыз әле, ветераннар
Картаймагыз,әй,тынгысыз җаннар!
Сезгә тиеш әле бик күп язлар,
Сезгә тиеш әле бик күп назлар. (Хәкимҗан Халиков)
Хөрмәтле ветераннар! Бүген сезнең, һәркайсыгыз алдында баш иябез, мең-мең, рәхмәт Сезгә!

**Җыр: " Һәрвакыт булсын кояш."**

# ХӘТЕР
## (Класс сәгате эшкәртмәсе)

**Махубрахманова Ландыш Тәзбир кызы,**
**Сарман муниципаль районы**
**Зур Нөркәй урта гомуми белем бирү мәктәбенең**
**башлангыч сыйныф укытучысы**

**Максат.** Укучыларны әби-бабаларның, авылдашларның Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән батырлыклары, тырыш, аяусыз көрәшләре, хезмәтләре белән таныштыру, сугыш афәтенең коточкыч фаҗига булуын төшендерү, бу җиңү миллионлаган совет халкының фронтта, тылда фидакарь көрәше, хезмәте нәтиҗәсе икәнен аңлату; 9-15 яшьлек балаларның Җиңүне якынайтуга керткән өлешләре турында мәгълүмат бирү; укучыларны фикер йөртүгә өйрәтү аша сугыш ветераннарына хөрмәт-ихтирам хисләре, кешелеклелек сыйфатлары, җаваплылык, Ватанга мәхәббәт хисе тәрбияләү.

**Материал:** “Сабантуй”, “Ватаным Татарстан” газетасыннан материаллар.

**Җиһазлау.** Бөек Ватан сугышы чорын чагылдырган әдәби әсәрләр күргәзмәсе, “Бөек Җиңүгә 70 ел”темасына балаларның рәсемнәре, кул эшләре; тактаның сул ягында кара белән язылган сугыш турында плакат; уң ягында тынычлык турында кызыл белән язылган плакат, презентация.

Дәрес барышы

**Укытучы:**

– Хәерле көн, укучылар, хөрмәтле кунаклар. Бүгенге сыйныф сәгатен башлап җибәрик.

Гомер узган саен тынмый күңел –
Үткәннәргә хәтер еш кайта.
Тыныч көндә авыр тойгы булып,
Сугыш яраларны кузгата.

Хәтердән уела күп нәрсә,
Онытыла иң гүзәл яз, кышлар.
Онытылмый үзенең иңендә
Ил данын күтәргән язмышлар.
Вакытлар үтүгә сүрелеп,
Сүнәләр иң якты балкышлар.
Сүнмиләр, яктылык сибәләр
Көрәштә кабынган язмышлар.

Укучылар, әйтегез әле, тиздән бездә нинди бәйрәм була? *(Бөек Җиңү бәйрәме)*. Әйе, тиздән бөтен илебез белән Бөек Җиңүнең 70 еллыгын билгеләп үтәчәкбез. Бөек Ватан сугышының дәһшәтле һәм фаҗигале көннәре елдан-ел ераклаша бара. Әмма халкыбыз 1418 көн дәвам иткән ул коточкыч вакыйгаларны һич оныта алмас. Сугышта 27 миллионнан артык совет кешесе һәлак булды, дистәләрчә миллион хатын-кыз тол, бик күп балалар ятим калды, инвалидлар саны бик күп булды. Илебез ярым җимерек хәлгә килде, халкыбыз күпме кайгы-хәсрәт кичерде. Сугыш кырында һәлак булучыларны барлау максатыннан, республикада 23 томлык “Хәтер китабы” басылып чыкты. 1992 нче елда Сарман районыннан сугыш кырында 1915 кеше үлеп калды дип исәпләнгән булса, “Хәтер китабы” басылгач, 1996 нчы елны, сугышта үлеп калучыларның төгәл саны 6866 кеше икәнлеге билгеле булды. Безнең Нөркәй авылыннан 1941 нчы елда 400 кеше Ватан азатлыгы өчен көрәшкә чыгып китә. “Бер кайтмасак, бер кайтырбыз”, дип китсәләр дә, 285 авылдашыбыз яу кырында мәңгелеккә ятып кала. Туган җиребез өчен башын салган бу батырларны онытырга безнең хакыбыз юк.

**Укучы.**

Зур сынаулы еллар килгән чакта
Беленә икән кемнең кемлеге.
Бер минутлык тынлык белән
Искә алыйк бүген без сезне.

*Бер минут тынлык.*

**Укытучы:** Сүзне укучыларга бирик әле, алар нәселдә булган сугыш ветераннары, аларның сугышчан бүләкләре турында сөйләрләр.

*Укучылар сөйли.*

**Укытучы:** Узган батырлык дәресләрендә без сезнең белән сугышчыларның героик батырлыклары, фашистларның ерткычлыгы турында сөйләшә башлаган идек. Хәзер шуларны искә төшереп китәрбез. *(Укучыларга табличкалар күрсәтелә, алар шул вакыйгалар турында сөйлиләр.)*

| |
|---|
| Брест крепосте |
| 22 июнь 1941 ел |
| 9 май 1945 ел |
| З.Хәсәнов |

**Укытучы:** Без сезнең белән язучы М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәримнәрнең, авылдашларыбыз Таһир абый, Габделхак абый, Фәүзия апа һ.б.ларның батырлыклары белән таныш. Укучылар, фашистларга каршы олылар гына көрәшкәнме?

*Укучылар чыгышы. Герой пионерлар, фашистларга каршы көрәшүче кызлар, малайлар турында сөйләшү.*

**Укытучы.** Сугыш булмаган урыннарда кешеләр фронтка кулларыннан килгәнчә ярдәм иткәннәр:

– 10 миллион данә җылы кием;
– танк һәм эскадрилья төзелешенә 262 миллион сум акча;
– 39 миллион пот бәрәңге;
– 131 миллион пот ашлык;
– 56 миллион пот ит.

1941-1945 елларда Татарстан басуларында 650 мең укучы һәм укытучы тырышып хезмәт куя. Иң беренче укучылар бригадасы Чистай районы Актау 7 еллык мәктәбендә оеша.

Безнең Нөркәй авылы кешеләре дә фронтка зур ярдәм күрсәтәләр. *(“Авыл тарихы”ннан саннар китерелә.):*

– танклар колоннасына – 150 мең сум;

– самолётлар эскадрильясына – спектакль куеп 13 мең сум.

**Укытучы**: Ә менә сезнең кебек малайлар һәм кызлар авылда нәрсәләр эшләделәр икән? Шул турыда сөйләү өчен сүзне авылыбызның мөхтәрәм кешесе Мәдинә апага бирәм. Сугыш башланганда аңа 11яшь була. *(Мәдинә апа чыгышы)*

**Китапханәче чыгышы**. *Ватан сугышына багышланган китап күргәзмәсе белән таныштыра.*

**Укытучы:** 1945 нче елның 9 нчы мае җиргә ачы күз яшьләре аша шатлык алып килә. Илебез халкы бердәм булып дошманнарны җиңүгә ирешә. Бөек Җиңү кешеләр күңеленә өмет, шатлык, ышаныч алып килә.

**Укучы:**

Сугыш бетте... Илем солдатлары
Кабат кайтты таныш җиремә.
Яшьлегебез чәчәк аткан илнең
Кырларында иген игәргә.

**Укытучы:** Бөек Ватан сугышы тәмамлануга быел 70 ел тула. Җиңү бәйрәме быел тагын шаулап узар. Ләкин кешеләр йөрәгендә сугыш калдырган яра – җәрәхәтләр һаман да сыкрый әле. Кадерле укучылар, әгәр сез, бу матур тормышта яшисез икән, иркен мәктәпләрдә укыйсыз икән, белегез: бу җирдә сезнең матур яшәвегез өчен меңләгән солдатларның каны түгелгән. Бу яшьлекнең, бу тормышның кадерен белегез, укучылар!

Исәннәрнең кадерен белик!
Үлгәннәрнең каберен белик!

**Укытучы:** Әйдәгез,бүгенге дәресебезне тынычлык турындагы җыр белән тәмамлыйк.

*“ Тынычлык” җыры башкарыла.*

# ӘХЛАК ТӘРБИЯСЕ-МӘҢГЕЛЕК ТӨШЕНЧӘ
## (Урта сыйныф укучылары өчен түгәрәк эшчәнлеге)

**Хисамова Фирая Мөхәммәт кызы,**
**Апас районы Биеш урта мәктәбенең**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Аңлатма язуы.**

Тәрбия – бербөтен, күпкырлы, киң колачлы. Ул һәрвакыт, һәр җирдә: урамда, өйдә, мәктәптә, һәрбер дәрестә, һәр тәнәфестә тормышка ашырыла. Мәктәптә әдәбият һәм ана теле, тәрбия дәресләрендә балаларны төрле яклап үстерү бара.

Мин тәрбия сәгатьләре һәм дәресләр белән генә чикләнмичә, әхлак тәрбиясе бирүнең нигезле, нәтиҗәле эш төрләрен кулланам. “Әхлак тәрбиясе-мәңгелек төшенчә” дип исемләнгән түгәрәк эше дә алып барам. Түгәрәк эшчәнлеге ярдәмендә балаларны халкыбызның мәдәният мирасы белән таныштыруны, аларның рухын баетуны, әхлагын камилләштерүне һәм төрле өлкәдә сәләтен үстерүне үз алдыма максат итеп куйдым һәм эшне төрле юнәлешләрдә оештырам.

Шәхеснең формалашуында һәм үсүендә әхлак тәрбиясенең ролен педагогика элек-электән исбатлап-раслап килгән. Әле борынгы грек философы Сенека ук: “Гыйлемлектә алга китеп тә әхлак ягыннан артта калган кеше алга китүдән дә бигрәк артка калып яши, – дигән гыйбарә әйткән. Шуңа да язучыларыбызның, шагыйрьләрнең, композиторларыбызның күңел җәүһәрләре үрнәгендә укучыларда әдәплелек, сабырлык, акыл көче, намуслы булу, күңел сафлыгы, тормышны ярату хисе тәрбиялим.

Үз эш тәҗрибәмә нигезләнеп, 2013 нче елда укытучылар өчен «Рухың сәламәт булса, җаның тыныч булыр» дип исемләнгән методик кулланма чыгару бәхетенә ireш-

тем. («Мәгариф-Вакыт» нәшр., 96 бит). Методик кулланмамда Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләренә таянып, дәрестә һәм сыйныфтан тыш чараларда рухи тәрбия белән шөгыльләнүнең күп кенә серләрен ачарга тырыштым.

Тормыш ыгы-зыгысында үз йөзен, кешелек горурлыгын югалтмый торган әхлаклы, чиста рухлы шәхесләр тәрбиялисе иде. Ә инде Ризаэддин Фәхреддин кебек шәхесләребезнең мирасын барлап, җентекләп өйрәнү, алар белән укучыларны таныштыру – төп бурычларыбызның берсе. Моннан күп еллар элек язылган ул рухи байлыклар, әхлак кагыйдәләре, тәрбия ысуллары бүген дә үз кыйммәтләрен югалтмаган. Р.Фәхреддиннең хезмәтләре гасырлар дәвамында тупланган, халык тәҗрибәсенә нигезләнгән һәм ул – югары әхлакый шәхес тәрбияләүдә мөһим чыганак. Р.Фәхреддин – үгет-нәсыйхәт бирү буенча тиңе булмаган әсәрләр калдырган шәхесләрнең берсе. Аның иҗат мирасыннан башка мәктәптә тәрбия эшен оештыруны күз алдына да китереп булмый. Бөек шәхесне без генә түгел, киләчәк буын да онытмасын, аны өйрәнсен, аның хезмәтләрен куллансын һәм аның белән горурлансын иде!

Мәктәптә үткәрелә торган дәрестән тыш эшләр укыту-тәрбия эшен оештыруда мөһим роль уйный. Моңа кичәләр, класс сәгатьләре, түгәрәк эшләре керә. Һәм бу эшләр дәресләрнең дәвамы итеп бәяләнә, нигездә белем һәм тәрбия бирү максатыннан чыгып эшләнә. Алар әхлакый һәм тәрбияви яктан уңай нәтиҗәләрен дә бирә.

Түгәрәк эшләре укучыларда белем алуга һәм фәнгә карата кызыксыну уяталар, балага күбрәк һәм киңрәк мәгълүмат бирәләр. Озак еллар мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыту дәверендә берничә төрле «Каләм тибрәтәбез», «Туган тел», «Алтын каләм», «Милли, рухи, әхлакый тәрбия» дигән исем астында түгәрәк эшләре алып барырга туры килде. Аларның һәрберсен оештыруда түбәндәге юнәлешләр күз уңында тотыла.

фән буенча алган белемнәрне тирәнәйтү;

фәнгә карата кызыксыну уяту;

сөйләм телен үстерү, ягъни аралашу сәләтен үстерү;

әхлаклы шәхес тәрбияләү;

укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү;

Түгәрәк эшләре планлы рәвештә алып барыла һәм ул дәресләрнең дәвамы буларак, укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп үткәрелә.

Бу дәресләрнең һәрберсендә әхлак темасы күтәрелә.

Кешелек дөньясының төп бурычы – яшь буынны яхшылыкны яманлыктан, гүзәллекне ямьсезлектән, югары хисләрне түбән хисләрдән аера белергә өйрәтү.

Программа урта сыйныф укучылары өчен төзелде.

**Программаның эчтәлеге: (102 сәгать, атнага 4 сәгать исәбеннән).**

**Максат:**

1. Әдәби әсәрләрне укыту процессында балаларга катлаулы ситуацияләргә, кешеләрнең психологиясенә, характерына тирән анализ ясарга өйрәтү һәм әхлакый тәрбия бирү өчен файдалану.
2. Күзгә күренмәс җепләр аша бала күңеленең түренә үтеп, анда кешелек дөньясының буыннан-буынга сакланып килгән тәрбия хәзинәләрен сеңдерү өчен уңай җирлек тудыру.
3. Кеше үсешендә ирешергә мөмкин булган бөтен яхшы якларны укучыларда тәрбияләү.

**Бурычлары:** 1. Балаларны җәмгыятьттәге әхлак кагыйдәләре, әхлак нормалары белән таныштыру.

2. Балаларның хисләрендә, аңында, тәртибендә әхлаклылык принципларына омтылыш тәрбияләү.

3. Уйланырга, нәтиҗә чыгарырга, үз фикерләрен дөрес, кыю әйтә, аңлата белергә өйрәтү.

**Программаның актуальлеге:** Белем бирүдә федераль дәүләт стандартларының яңалыгы – белем алуда уни-

версаль гамәлләрнең берсе коммуникатив гамәлләрнең камил формалашуы. Ягъни, укучының үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүгә әзерләү. Бу таләп – курсның актуальлеген раслаучы мөһим дәлил дә.

**Программаның структурасы:**

Программа 5 блоктан тора һәм алар темаларга бүленгән.

I нче блок: **Патриотик тәрбия.**

1. Тау ягының якты йолдызлары.
2. “Апас” якташлык җәмгыяте тарихыннан.
3. Халык хәтере – мәңгелек.
4. Күңелемә якын син, туган як.

II нче блок: **Халык авыз иҗаты һәм әхлакый тәрбия.**

1. Халкыбызның күңел бизәкләре.
2. Халык җәүһәрләре.
3. Сөембикә халык хәтерендә.
4. “Тәмле тел-дару, әче тел-агу”

III нче блок: **Тормыш фәлсәфәсе.**

1. Чын ир-егет һәм нәфис-нәзәкатьле кыз бала.
2. Тормыш яме – әнкәй, хатын-кыз.
3. Яхшылык ташны да эретә.
4. Гаилә-җылы учак.
5. Нәрсә ул бәхет?

IV нче блок: **Профориентация.**

1. Алда йөз юл- берсе синеке.
2. Замана яшьләренә ачык хат.

V нче блок: **Татар фәлсәфи фикере.**

1. Күренекле татар мәгърифәтчеләре.
2. Татар йөрәгендә син – театр.
3. Милли тәрбия нигезләре.

| | **Бүлекләр. (Һәр дәрес үрнәге бер бүлекне тәшкил итә).** | Сәг. саны |
|---|---|---|
| 1 | Кереш . “Кеше һәр яктан да гүзәл булырга тиеш.” Р.Фәхреддин. “Балаларга үгет-нәсыйхәт” | 5 |
| | -Тау ягының якты йолдызлары. (дәрес үрнәге)<br>-Апас турындагы җырларны тыңлау.<br>- Апас районындагы авылларга атап чыгарылган китаплар күргәзмәсе белән танышу. (Х.Гайнуллин “Гомер чакрымнары”, Х.Бәдретдинов “Борнаш иле”, Х.Гайнуллин “Апасым- гомер бишегем” һ.б.)<br>-Шәмбалыкчы авылындагы Ф.Насретдинов, Бану Вәлиева музеена экскурсия оештыру. Практик дәрес: Р.Фәхреддин «Нәсыйхәт» китабыннан үрнәкләр уку. (әңгәмә) “Гүзәл табигатьле Апасым” темасына сочинение язу. | 1<br>1<br>1<br><br><br>1<br><br>1 |
| | -Сөембикә халык хәтерендә. (дәрес үрнәге)<br>-Казан шәһәренә күңелдән сәяхәт.(Истәлекле урыннар, тарихи биналар, кино-театрлар, югары уку йортлары, спорт сарайлары белән танышу, презентацияләр карау).<br>-Легендалар уку.<br>-Сөембикә бәетен уку, фикер алышу.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин «һәр милләт кешесе үзенең үткәнен белсен, үз тарихы белән дус булсын» әңгәмә. “Басып тора ярда Сөембикә...” темасына эссе язу. | 1<br>1<br><br><br>1<br>1<br>1 |
| | -Нәрсә ул бәхет? (дәрес үрнәге)<br>-Сәламәтлек-иң зур байлык.<br>- Табигать кочагына сәяхәт.<br>- И.Юзеевның “Таныш моңнар” поэмасында бәхет темасы. Резидәнең монологына бәя бирү.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин «Алдыгызда олуг сәгадәт илә озын рәхәт вә бәхет сезне каршылап көтәдер» әңгәмә.  “Мин бәхетлеме?” темасына эссе язу. | 1<br>1<br>1<br>1<br><br>1 |
| | -Халык җәүһәрләре. (дәрес үрнәге)<br>-Халык авыз иҗаты әсәрләре . Әкиятләр, бәетләр, мөнәҗәтләр, кыска җырлар, мәзәкләр, мәкальләр уку. -“Тапкырларга табышмак” уены оештыру. | 1<br>1<br><br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| | - Мөнәҗәтләр иҗат итүче, аларны оста башкаручы, тәмле телле, ак яулыклы апалар (әбиләр) белән очрашу уздыру.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин: «Тарих-ул азмы-күпме кешелек хакында белем алу һәм берәр төрле үз карашын тудыру өчен үрнәк табу, шуннан соң аны файдаланудыр» әңгәмә. Шигырьләр, әкиятләр иҗат итү. | 1<br><br>1 |
| | -Күңелемә якын син, туган як. (дәрес үрнәге)<br>-Туган авылым, районым темасына әңгәмә.<br>-Эшкә батыр, сүзгә тапкыр авылым кешеләре белән очрашу уздыру.<br>-Туган авылның гүзәл урыннарын фотога төшерү, альбом туплау.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин «Үзегезне яхшы исем берлә искә алырлык эшләр калдырыгыз» әңгәмә. “Туган авылым” темасына эссе язу. | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | - Гаилә-җылы учак. (дәрес үрнәге)<br>-Тәрбия-гаиләдән башлана. “Без китап укырга яратучы гаилә” темасына гәҗит чыгару.<br>- “ Бу безнең тату гаилә” дигән темага альбом әзерләү.<br>- “Түгәрәкнең тәрбияви әһәмияте” дигән темага әти-әниләр җыелышы үткәрү.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин:» Изге балалар күктән килмиләр, ә бәлки гаиләдә җитешәләр» әңгәмә. “Минем шәҗәрәм” темасына сочинение язу. | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | -Тәмле тел-дару, ачы тел-агу. (дәрес үрнәге)<br>-Сөйләм әдәпләре. Сөйләм телен үстерү юллары.<br>-Тәмле телле , киң күңелле кадерле дәү әниләр белән очрашу үткәрү.<br>-Сәнгатьле уку дәресе.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин»Адәм баласының күңелендә булган йомшаклык һәм катылык кебек нәрсәләрне ачып бирүче... нәрсә-телдер» әңгәмә. “Миңа үрнәк булырдай кеше” темасына сочинение язу. | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | -Халык хәтере-мәңгелек. (дәрес үрнәге)<br>-Район үзәгендәге “Туган якны өйрәнү” музеена, мемориалга экскурсия оештыру. | 1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| | -Авылдашыбыз, Советлар Союзы Герое Д.И.Горбуновны, аның тормышын яхшы белгән абый-апалар белән очрашу уздыру.<br>- Музейга экспонатлар тапшыру. Һәр кечкенә табылдыкның зур әһәмияте булырга мөмкин.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин «Тарих зур тәрбияви әһәмияткә ия тормыш мәктәбе вазифасын үти» әңгәмә. “Авылым горурлыгы –герой Горбунов” темасына сочинение язу. | 1<br>1<br>1 |
| | -Алда йөз юл- берсе синеке. (дәрес үрнәге)<br>-Төрле профессия кешеләре белән очрашу.<br>- Туфан Миңнуллинның “Үзебез сайлаган язмыш” әсәре буенча фикер алышу. Образларга характеристика бирү.<br>-Яңа гына укуны тәмамлап югары уку йортларында белем алучы студентлар белән очрашу.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин» Гыйлем юлы-бер кадерле юлдыр. Шулай булса да, очы-бәхеткә, ахыры камиллеккә барып туктыйдыр» әңгәмә. “Алда йөз юл- берсе минеке” темасына сочинение язу. | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | -Яхшылык ташны да эретә. (дәрес үрнәге)<br>-Изге гамәлләр генә кылыйк, сугыш һәм тыл ветераннарына ярдәм итик.<br>-Күрше районнардагы картлар йортларына, балалар йортларына, Балтай авылында урнашкан сәламәтлекне терләндерү үзәгенә концерт номерлары әзерләп бару.<br>-Изгелек, мәрхәмәт, яхшылык темаларына төрле халык мәкальләрен китапчык итеп туплау.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин «Кем дә булса, башкаларның гаепләрен тикшергәнче, беренче чиратта үзендә булган кимчелекләрне бетерергә, үзен яхшы кеше итеп тәрбияләргә тырышсын» әңгәмә. “ Изгелек җирдә ятмый” темасына сочинение язу. | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | -“Апас” якташлык җәмгыяте тарихыннан. (дәрес үрнәге)<br>-Апас җирлегеннән чыккан шәхесләребезне барлау.<br>-Туганлык, дуслык, якташлык төшенчәләре турында әңгәмә кору.<br>- Х.Гайнуллинның “Апасым –гомер бишегем” һәм “Тау ягының моңлы җырчысы” китапларына күзәтү ясау.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин» Дөньяда иң кирәкле гыйлемнәрнең берсе-кеше тану гыйлемедер» әңгәмә.“Данлы якташларыбыз ” темасына эссе язу. | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| | -Халкыбызның күңел бизәкләре. (дәрес үрнәге)<br>-Калфак, читек, түбәтәйләр тарихы турында әңгәмә.<br>-Гәҗит-журналлардан халкыбызның күңел бизәкләрен табу, альбом итеп ясау.<br>-Халкыбызның күңел бизәкләрен рәсемгә төшерү, шулардан күргәзмә оештыру.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин» Мәмләкәтләрнең ныгулары, өммәтләр вә милләтләрнең сәгадәт белән дәвамнары исә җирләре киң вә җан хисаплары күп булу белән түгел, бәлки гыйлем вә һөнәрләре, сәнәгать вә мәгърифәтләре беләндер» әңгәмә. Армия хезмәтенә китүче егетләргә бүләк-кулъяулык чигү. | 1<br>1<br>1<br><br>1<br><br>1 |
| | -Тормыш яме - әнкәй, хатын-кыз. (дәрес үрнәге)<br>-Ана образына дан җырлаган шагыйрьләр, әдипләр, композиторлар иҗаты белән танышу.<br>-Әниләр темасына багышланган шгырьләр, җырлар өйрәнү. Мәктәп линейкасы вакытында чыгыш ясау.<br>-Туфан Миңнуллинның “Әниләр һәм бәбиләр” әсәре буенча фикер алышу. Гөлфинә һәм Дилемма образларына характеристика бирү.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин» Сезгә иң якын кешеләр, әлбәттә, ата-аналарыгыздыр. Шуның өчен аларга һәрвакытта итәгатьле булыгыз...» әңгәмә. “Газиз әнием” темасына эссе, яисә шигырь язу. | 1<br>1<br><br>1<br><br>1<br><br>1 |
| | -Замана яшьләренә ачык хат. (дәрес үрнәге)<br>-Армиядә хезмәт итүче авылдаш егетләргә хат язу.<br>-Яңа гына армия хезмәтеннән кайткан солдат белән очрашу уздыру. | 1 |
| | -Мәктәп формасы турында әңгәмә кору. “Мәгърифәт” гәҗитендә басылган “Миңа кыска итәк килешә” дип исемләнгән мәкалә турында фикерләр. Практик дәрес: Р.Фәхреддин. «Кешенең матурлыгы- аның тәрбияле, эшчән, намуслы булуында, олыларны-олы итеп, кечеләрне кече итеп яши белүендә» әңгәмә.“Яшьтәшемә ачык хат” темасына хат язу. | |
| | -Татар йөрәгендә син - театр. (дәрес үрнәге)<br>-Мәдәният дөньясында. Театрның тәрбия көче турында, театр артистлары турында әңгәмә.<br>-Г.Камалның “Беренче театр” спектакленнән өзекне сәхнәләштерү.<br>-Тормыш- театр, ә без-артистлар темасына әңгәмә кору. | 1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Практик дәрес: Р.Фәхреддин»Хәлбуки һәрбер кеше үз кулыннан килгән кадәр эш эшләргә, байлык вә һөнәр һәм дә сәнгать тугрылыгында милләтнең күтәрелүенә ярдәм кыларга тиешле» әңгәмә. “Театр-яктылыкка, нурга илтә” темасына сочинение язу. | 1<br>1<br>1 |
| | -Милли тәрбия нигезләре. (дәрес үрнәге)<br>-Төрле милләт вәкилләре арасындагы дуслык, толерантлык. Уен, бәйрәмнәр, йолалар, гореф-гадәтләр турында әңгәмә кору.<br>- Аулак өй” күренешен сәхнәләштерү”.<br>-Дәү әниләр белән очрашу оештыру.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин « Адәм баласы үз-үзен тәрбияләргә һәм камилләштерергә тиеш, буй җиткән һәр кеше үз-үзен тәрбияли ала» әңгәмә. “Милләтем- минем киләчәгем” темасына хикәя язу. | 1<br>1<br><br>1<br>1<br>1 |
| | -Чын ир-егет һәм нәфис-нәзәкатьле кыз бала. (дәрес үрнәге)<br>-“Татар милли педагогикасы”(Р.Х.Шәймәрданов, Ә.Н.Хуҗиәхмәтов), “Милли тәрбия нигезләре” дигән китапларга күзәтү ясау.<br>-Киңәшләр, теләкләр. Төрле илләрдәге тәрбия үрнәкләре белән танышу.<br>-Ялкынлы яшьлекнең яме темасына әңгәмә.<br>Практик дәрес: Р.Фәхреддин» Гыйффәт.Инсаннарның кыйммәтләре гыйффәтләренә күрә булыр.» («Җәмигуль кәлим шәрхе китабыннан») әңгәмә. “Мин чын кешеме?” темасына эссе язу. | 1<br>1<br><br>1<br><br>1<br>1 |
| | -Күренекле татар мәгърифәтчеләре. (дәрес үрнәге)<br>-Мәгърифәтчеләрнең портретлары, аларның хезмәтләре белән танышу.<br>- Үрнәк өчен Каюм Насыйри иҗатында халык җәүһәрләре дигән әзер реферат белән танышу.<br>-Районыбыз редакциясендә 30 ел журналист булып эшләгән Азат абый Сөнкишев белән очрашу.<br>Практик дәрес: Рефератлар әзерләү һәм яклау. | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | Презентацияләр төзү. Түгәрәкнең еллык эшчәнлеген яктырткан “Әхлак тәрбиясе- мәңгелек төшенчә” дип исемләнгән гәҗит чыгару. | 5 |
| | Йомгаклау дәресләре. Бу дәресләрдә укучыларның иҗади эшләрен һәм презентацияләрен тәкъдим итү оештырыла. Дәрес конференция уздыру. Нәтиҗәләр ясала. | 2 |

***Үзем турында***

*Мин сугыш ветераны баласы. Әтием – Сәлимов Мөхәммәт Сәлимулла улы (1924) дәһшәтле сугыш кырын кичкән кеше. Ул II группа инвалид булып яшәде, гомере буе аягынапротез киеп йөрүенә карамастан нинди генә эшләр башкармады, алтын куллы кеше иде.*

*Язлар җиткәндә аеруча моңсулана һәм көрәштәш дусларын искә төшерә иде. Әтием безгә сугыш турында еламыйча сөйли дә алмый иде. Мин ул сөйләгәннәрдән чыгып шигырь иҗат иттем.*

*Әнием – Сәлимова Мөнирә Сабир кызы (1924) да ул михнәтле елларның авырлыгын үз җилкәсендә нык татыган, тәртәнең төбенә җигелеп эшләгән, авырлыклар алдында югалып калмый торган батыр йөрәкле кеше иде. Без биш баланы тәрбияләп кеше иттеләр, олы тормыш юлына чыгардылар. Шигырьләрем газиз әти-әнием рухына дога булсын иде.*

**Әтием хәтирәләре.**

Аяз көнне яшен суккандай,
Фашист камап алды дөньяны.
41 нең июнь аенда
Илгә япты кара юрганын.

Зур көрәшкә чакырып ил дәшә,
Берни эшләп булмый бүтәнчә.
Һичнидән дә үзен аямыйча,
Халкым күтәрелде көрәшкә.

Озакка сузылган сугышта
Җиңүне яуларга ирештек.
Учларга йомарлап йөрәкне,
Яңадан яшәргә керештек.

Җиңсәк тә рәхимсез фашистны,
Элсәк тә без Җиңү байрагын,

Хәтердән чыкмыйлар ул еллар-
Тәннәрдә күп төрле яра бар.
Дәһшәтле, канкойгыч сугышның
Куркыныч көннәре хәтердә.
Вәхшәтне, михнәтне әле дә
Күрәм мин төннәрен төшемдә.

Гомер узды, бик күп сулар акты.
Ничә кабат килде Җиңү язы.
Бәйрәм таңын каршы алачак,
Исән калганнарның бик азы.

Булмасын сугышлар һичкайчан
Түкмәсен күз яшен аналар.
Кояштай елмаеп яшәсен,
Бәхетле булсыннар балалар!

**70 нче Җиңү язы.**
Әйләнә дә килә язлар җиргә,
Назга төреп бөтен дөньяны.
Күз алдына китергәндәй булам,
45 тә килгән Җиңү язын.

Нык ышанып көткән халкым,
Бөек Җиңү көне киләсен.
Зур югалту, хәсрәт, кайгы аша,
Яз китергән Җиңү иртәсен.

Бу көн илгә бәхет алып килгән,
Халкым өчен чиксез зур бүләк.
Күкрәкләргә сыймас булган хәтта,
Шатлыгыннан ярсып һәр йөрәк.

Язлар килгән саен табигатькә,

Җиңү көнен бәйрәм итәбез.
Без бурычлы сезнең алда, диеп,
Ветеранга рәхмәт әйтәбез.

Ветераннар, мәңге тынмас җаннар.
Утны-суны кичкән батырлар.
Алар үлмәс, алар нур булып,
Йолдыз булып күктә балкырлар.

**Сугышлы уйныйлар малайлар.**
Сугышлы уйныйлар малайлар,
Уйныйлар шулкадәр мавыгып.
Мылтыктан аталар янәсе,
Дошманның йөзенә каратып.
Сугышлы уйныйлар малайлар,
Көн буе гөр килә тирә-як.
Кулларга талчыбык алалар,
Янәсе, сугышка баралар.
Сугышлы уйныйлар малайлар,
Мәгънәсе билгеле аларга.
Атланып агач атларга,
Баралар Ватанны сакларга.
Сугышлы уйнаган малайлар,
Бик тиздән егетләр булырлар.
Һичнидән куркуны белмәсләр,
Илебез сагында торырлар.
Уеннар чынга ашмасын!
Күзләрдән кайнар яшь акмасын!
Илебез тынычта яшәсен!
Сугышлар күрергә язмасын!

*Хисамова Фирая Мөхәммәт кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы, «Рухың сәламәт булса, җаның тыныч булыр» методик кулланма авторы. «Вакыт-Мәгариф» нәшрияты – 2013 ел.*

# ПРОЕКТ “ТУГАН ЯГЫМНЫ ӨЙРӘНӘМ”

**Исмәгыйлева Ә.М., Габдрахманова Л.Р,**
**Махубрахманова Л.Т., Габдрахманова Э.М.,**
**ТР Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй**
**урта гомуми белем бирү мәктәбенең**
**сыйныф җитәкчеләре**

Авылым, син бөек илкәемнең,
Җанга якын газиз почмагы.
Җылытып яшәр гомер буе безне
Туган җирнең газиз почмагы. (Р.Закиров)

Бу проект укучы шәхесен формалаштыруда, чын патриот һәм гражданин тәрбияләүдә зур роль уйный. Әлеге проект укыту процессында катнашучы укытучы һәм укучыларны гына түгел, әти-әниләрне дә яшь буынга тәрбия бирү эшенә җәлеп итә. “Безнең яңа мәктәп” милли белем бирү инициативасы ата-аналар белән эшләүне үзәккә куя. Бүгенге мәктәп гаилә белән тыгыз элемтәдә булырга тиеш. Балалары белән бергә белем бирү оешмаларына килү ата-аналар өчен дә кызыклы һәм зарури булырга тиеш.

**Актуальлелеге:** Ватанга, гаиләгә, туган як табигатенә мәхәббәт, гражданлык хисе тәрбияләү – РФ нең “Мәгариф турында”гы законында белем бирү өлкәсендә дәүләт политикасы билгеләгән төп принципларның берсе. Анда Ватанын сакларга һәм якларга сәләтле, физик һәм әхлакый яктан сәламәт шәхес тәрбияләү турында сүз бара. Бүгенге көндә Ватан язмышына битараф булмаган патриотлар тәрбияләү белем һәм тәрбия бирү системасының төп бурычы.

**Проблемасы:** Туган якны өйрәнү аша гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләп буламы?

Эш барышында укытычылар түбәндәге проблемалар белән очрашалар:

- туган як тарихы турында җитәрлек мәгълүмат булмау
- кирәкле тема буенча укучыларда мөстәкыйль рәвештә мәгълүмат туплау күнекмәсе булмау
- алган белемнәрне башкалар белән уртаклаша белмәү

**Максаты:**

- туган авыл турында күзаллау формалаштыру барышында ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтне ныгыту
- туган як һәм гаилә язмышы өчен җаваплылык хисе тәрбияләү

**Бурычлар:**

- мәктәп һәм гаилә шартларында ата-аналарны балалары белән бергә актив эшчәнлеккә тарту
- укучыларның туган авыл турындагы белемнәрен баету һәм системалаштыру
- рәсем сәнгате эшчәнлегендә, дизайн өлкәсендә, сөйләм телен үстерүдә балаларның практик күнекмәләр тупланмасын камилләштерү
- укучыларны белешмә материаллардан, фәнни-популяр әдәбияттан, хәзерге заман мәгълүмат чыганакларыннан, көндәлек матбугаттан файдаланырга өйрәтү
- укучыларның иҗади күзаллавын һәм фантазиясен үстерү. Ата-аналарга балалары белән берлектә иҗади сәләтләрен күрсәтергә мөмкинлек тудыру

**Катнашучылар:** Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй урта гомуми белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныф укучылары һәм аларның ата-аналары.

**Проектны тормышка ашыру вакыты:** сентябрь 2013 ел – май 2015 ел .

**Төре:** иҗади, дәвамлы, гаилә белән күмәк эш.

**Эшчәнлек төре**: иҗади эзләнү, тикшерү һәм

нәтиҗәләр ясау.

**Куллану өлкәсе:** мәдәниятта, ингвистикада, туган якны өйрәнүдә.

**Проект эшчәнлегенең нәтиҗәләре**:

• фотосурәтләр, рәсемнәр, кулдан эшләнгән әйберләр, стена газеталары, стендлар

• презентацияләр

**Мәгълүмати-техник чаралар белән тәэмин итү:** район, мәктәп, авыл китапханәләре, интернет, музей, тарих кабинеты, мәктәпнең архив материаллары .

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

Укучылар өчен:

– тапшырылган эшкә җаваплы караш

– укучыларның мөстәкыйльлеген, активлыгын, башлап йөрүчәнлеген үстерү

– алган белемнәрен тормышта куллана белү

Педагоглар өчен:

– һөнәри осталыкны күтәрү

– укыту һәм тәрбия процессында яңа алымнар куллану

– һөнәри һәм шәхси үсеш

– һөнәри осталыкны пропогандалау

Ата-аналар өчен.

– шәхси аң дәрәҗәләрен үстерү, бала һәм ата-ана арасындагы бәйләнешне ныгыту, белем һәм тормыш тәҗрибәләрен балаларга бирә белү.

**Проектны тормышка ашыру принөиплары:**

1) Үсеш принцибы – шәхес үсешендә төгәл юнәлешне чагылдыра.

2) Дифференцияләштерү һәм индивидуальләштерү принцибы – һәр баланың һәм аның гаиләсенең нәрсәгә сәләтле икәнен күрсәтүгә мөмкинлекләр тудыруны күздә тота.

3) Диалогик аралашу принцибы – иҗади проектта

катнашучыларның бер-берсен аңлауларын, фикерләр ачыклыгын, ихласлылыгын күрсәтә.

4) Аңлаешлылык принцибы – эшне оештырганда укучыларның яшь үзенчәлекләре, әзерлек дәрәҗәсе, гаиләдәге мөнәсәбәтләрнең үзенчәлеге күздә тотыла.

5) Эзлеклелек принцибы – максатка ирешү уку һәм тәрбия юнәлешендәге мөхим мәсьәләләрне хәл итү юлы белән тормышка ашырыла.

**Проектны тормышка ашыру формалары һәм методлары:**

– танып-белү шөгыльләре, экскурсияләр;
– нәтиҗәле эшчәнлек;
– фотокүргәзмәләр, рәсем һәм кулдан эшләнгән әйберләр күргәзмәләре.

## Проектның төрле этапларында укучыларның эшчәнлеге

| № | Этаплар | Бурычлар | Укучылар һәм ата-аналарның эшчәнлеге | Укытучының эшчәнлеге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Әзерлек | Теманы сайлау, максатларын ачыклау, проектны тормышка ашыру вакытын билгеләү, проектта катнашу өчен гаилә группалары төзү, мәгълүмат чыганакларын билгеләү | Мәгълүматларны ачыклау; Биремнәр буенча фикер алышу. Уңышка ирешү критерийларын сайлау һәм нигезләү | Укучылар һәм ата-аналарның эшчәнлеген оештыру; түгәрәк өстәл янында ата-аналар белән проектның максатлары турында фикер алышу; үтенечләр буенча ярдәм итү; күзәтү |
| 2. | Эш барышы | Проект идеяләрен ачучы эшләрне башкару | Мәгълүмат туплау: китапханәләрдә булу, проект проблемасына кагылышлы әдәбитны өйрәнү, в/ф карау, өлкәннәр белән әңгәмәләр, интернет, экскурсия эшчәнлеге. Эшләрне башкару һәм  нәтиҗәләрен туплау, иҗади хикәя» Минем туган ягым». Рәсем һәм гаилә белән кулдан эшләгән әйберләр конкурсы фотокүргәзмә «Минем туган авылым» | Туган авыл турында тематик сыйныф сагатьләре, индивидуаль әңгәмәләр үткәрү:”Авылымның чишмәләре һәм таулары”, “Мин яшәгән урам”, «Минем гаилә». Туган якны өйрәнү музеена, ата-аналарның эш урыннарына экскурсияләр оештыру |
| 3. | Рефлексия | Проект эшчәнлегенә нәтиҗә ясау | Киләчәктә куллану максатыннан “Минем туган авылым” темасына мәгълүматлар банкы туплау | Проект эшендә катнашучыларга рәхмәт белдерү |

## Эш планы

| Бүлекнең темасы | Эшнең эчтәлеге | Проект эшчәнлегенең нәтиҗәләре |
|---|---|---|
| «Авылымның урамнары һәм тирә-ягы» | 1.Экскурсияләр һәм күзәтүләр. Табигый материаллар җыю.<br>2.Ата-аналар белән иҗади күмәк эш " Алтын көз".<br>3. Гаилә белән эзләнү-тикшерү эше "Безнең урам тарихы".<br>4. "Авылымның чишмәләре һәм таулары." | Гаиләнең кул эшләре күргәзмәсе "Көзге фантазия", "Авылым урамнары", "Авылымның чишмәләре һәм таулары" темаларына мәгълүматлар банкы төзү |
| "Зур Нөркәй авылы – минем кече Ватаным" | 1. Минем авылым (Район, республика картасындагы урыны, авылның тарихы, авыл турында җыр).<br>2. Туган якны өйрәнү музеена экскурсия.<br>3.Гаилә белән иҗади инша.<br>4. "Авылым һәйкәлләре" | Уен "Нәрсә? Кайда? Кайчан?"(авыл тарихы, аның кешеләре)<br>Рәсем күргәзмәсе "Минем авылым"<br>Альбом "Зур Нөркәй авылы – минем кече Ватаным"<br>Гаилә иншаларына конкурс "Газиз туган ягым"<br>"Авылым һәйкәлләре" (пластилин) |
| "Ватан каян башлана?" | 1. Ата-аналарның эш урыннарына экскурсия. | Фотокүргәзмә "Минем авылым", стенд ясау. |
| | 2. Авылыбызның күренекле кешеләре белән очрашу.<br>3. КВН "Үскәч кем булырга?"(һөнәрләр турындагы белемнәрен баету).<br>4. Ата-аналар белән күмәк иҗади эш "Кыш бабай остаханәсендә". | Авылдаш язучылар Н.Г. Гарифҗанова, Н.В.Мостафиннар белән очрашу кичәсе.<br>Рәсем күргәзмәсе "Үскәч сайлаячак һөнәрем"<br>Конкурс "Кыш бабай остаханәсендә" |
| Гаиләнең татулыгы - җан тынычлыгында | 1. Рәсем күргәзмәсе "Минем гаилә".<br>2. Гаилә остаханәсе. | Гаиләнең кул эшләре күргәзмәсе:"Әниемнең тынгы белмәс куллары", "Әтием куллары" |

| | | |
|---|---|---|
| | 3. “Безнең өчен бик кадерле һәм изге кеше...”.<br>4.”Кояш булганда җылы, әни булганда рәхәт”. | белән кошлар өчен җимлекләр” “Гаилә архивыннан”- Бөек Ватан сугышында катнашкан бабайларыбыз турында истәлекләр<br>Гаилә бәйрәме “Күңелле сюрпризлар көне” |
| Мин - туган илемнең яшь гражданины | 1.”Әти, әни һәм мин – спорт гаиләсе”.<br>2. “Яхшы булса да торган җир, сагындыра туган ил”.<br>3.Йомгаклау шөгыле– презентация “Безнең дус гаилә”. | Рәсем күргәзмәсе ”Әтием – Ватан сакчысы”<br>Презентация “Безнең дус гаилә”, гаилә газеталарын яклау. Туган як турында белемнәрне ныгыту максатыннан викториналар, бәйгеләр, кичәләр, әңгәмәләр үткәрү. |

Иҗади проект өстендә эшләү барышында укучылар өйрәнәләр:

– коммуникатив эшчәнлек күнекмәләренә;
– төрле мәгълүмат чараларын файдаланып, мөстәкыйль белем алырга, күзаллауларын үстерергә;
– план буенча эшләү күнекмәләре булдырырга;
– логик фикер йөртергә, анализларга, гомумиләштерер-гә,нәтиҗәләр ясарга;
– иҗади сәләтләрен үстерергә.

**Проект эше – фотоларда**

Авыл табигатенә экскурсия.

Авылыбыз Минзәлә елгасы буена урнашкан. Минзәләнең ярларыннан бик күп чишмәләр бәреп чыккан. Без бик теләп табигатьне күзәтәбез. Болыннарындагы үсемлекләрнең төрләрен өйрәнәбез, чишмәләрен чистартабыз, тауларында тәгәрәп уйныйбыз. Чишмә-тауларның атамаларының килеп чыгышлары турында материал туплыйбыз, фикер алышабыз.

Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәннәрне онытма син!
Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен,
Ни иккәнен, ни чәчкәнен,
Нинди уйлар,нинди моңнар,
Безгә калдырып киткәннәрен.
(Равил Фәйзуллин)

Мәктәбебезнең тарих музеенда без еш булабыз.



**Өлкәннәрне олылыйк!**

1 нче октябрь көнне “Өлкәннәр көне” үткәрдек. Әлеге олы бәйрәмгә без әби-бабайларны чакырдык. Көн иртәнге яктан ук искиткеч матурлыгы белән таң калдырды. Кояш та ул көнне мул итеп җылысын бар дөньяга сипте. Һәрберебез әби-бабайларга өйдән чәчәкләр алып килдек.

Өлкәннәребез һич авырсынмыйча, сыкрануларын онытып, бәйрәмгә килделәр. Безнең бәйрәм рухыбыз аларга җылылык, бертөрле куаныч бирде. Күзләре шатлыктан елмайды, оныкларының игътибарын тою – үзләренә яшәргә омтылыш, өмет өстәде.

Бәйрәмдә без биедек, җырладык, уеннар уйнадык. Әби-бабайлар үзләренең оныкларыннан бәйрәм сәламен кабул иттеләр, уч төпләре кызарганчы кул чаптылар. Сәхнәдә “Әпипә” биюе башкарылганда, кайбер әби-бабайлар яшь чакларын искә төшереп утырдылар. Менә-менә сәхнәгә чыгып, биеп китәрләр кебек тоелды алар безгә. Чәчәк букытлары белән дә күмгәч, тамаша залы аллы-гөлле болынга әверелде. Барлык оештыручыларга, укучыларга рәхмәт әйтеп, әби-бабаларыбыз безне алкышларга күмделәр.

Концерт тәмамлангач, бәйрәм мәктәп ашханәсендә дәвам итте. Тәмле ризык-чәйдән авыз итеп, безнең һәм апалар тарафыннан күрсәтелгән игътибар, наздан, җылы сүздән күңелләренә шифа алып, өйләренә таралдылар.



**Әбиләр белән бию үзе бер бәхет...**



**Бабай белән ярышуга ни җитә!**



**Безнең өчен бик кадерле һәм изге кешеләр.**




**“Әбиемнең күңел сандыгы” темасына сыйныф сәгате үткәрдек.** Сыйныф сәгатенә әзерлек барышында без борынгы бизәнү әйберләре , милли киемнәр, һөнәрләр турында бай материал тупладык.

**Авыл тарихы, анның кешеләре турында “Нәрсә? Кайда? Кайчан?”** уенында башлангыч сыйныф укучыларының “Күпне белүчеләр”командасы укытучыларга каршы уйнадылар һәм үзләренең нәрсәгә сәләтле икәнен күрсәттеләр.







**Авылыбыз шагыйрәсе, мәктәбебезнең математика укытучысы Нурия Гомәровна белән очрашу күңелләрдә сакланыр.**

**Әти-әниләрнең эш урыннарына экскурсияләр.**

Безнең авылда ипи пешерү пекарнясы бар. Анда күп еллардан бирле тәмле ипиләр, күмәчләр, камыр ризыклары пешерәләр.Нөркәй ипиенең даны еракларга таралган.

Минем Зөлфия әбием һәм Расих бабам шунда хезмәт куялар.Әбием ипи пешерүче, ә бабам мичкә ягучы булып эшли. Ипи тәмле булып күпереп пешсен өчен мичкә каен утыны ягалар. Икесе дәүз эшләрен яратып, күңел биреп башкаралар. Ипи пешерүчеләрзур-зур казаннарда күпереп торган камыр әзерлиләр. Аларга электрболгаткычы да ярдәм итә. Әзер камырны калайларга салып кабарталар да мичкә тыгалар. Тирә-юньгә хуш ис таратып ипи пешеп чыга. Әбиемнең кулларыннан да яңа пешкән икмәк исе килеп тора. Әзер ипине,төрле камыр ризыкларын машиналар белән кибетләргә тараталар. Аларны һәркайда яратып алалар, мактап ашыйлар.



Без, I-IV сыйныф укучылары, анда экскурсиядә булдык. Ипи пешерү цехының җитәкчесе Ризванова Роза апа безгә ипи пешерү серләрен аңлатты, киләчәктә үзләренә алмаш булырга чакырды. Безне яңа пешкән кайнар ипи, тәмле чәй белән сыйладылар.

Экскурсия һәммәбезгә дә бик ошады. Без бу изге һөнәр ияләренең эше белән таныштык. Икмәкнең иң кадерле ризык икәнен, аңахөрмәт белән карарга кирәклеген тагын да ныграк аңладык.

**Кошлар – безнең дусларыбыз.**

Быел кыш кар күп яуды. Һава температурасының кискен үзгәреп торуы сәбәпле, бураннар да еш булды. Канатлы дусларыбызга азык табу көннән-көн авырлаша. Алар җим эзләп авыл тирәләренә елыша. Бигрәк тә мәктәп янын үз итте. Чөнки канатлы дусларыбыз өчен чын ашханә эшләп килә. Ашханәне һәрдаим барлап, карап тору эше безгә, башлангыч сыйныф укучыларына йөкләнде. Без үз эшебезне җиренә җиткереп башкардык, кошларны күчтәнәчләр белән сыйладык. Кыш ахырына якынлашып килә, ләкин җылы көннәргә ерак әле. Кошлар безнең ярдәмгә мохтаҗ.

Канатлы дусларыбызның төркем-төркем булып ашханәгә килүләре безне сөендерә.



**Моңсу бәйрәм.**

Бөек Җиңүнең 70 еллыгы якынлаша. Һәр җирдә бәйрәмгә әзерлек эшләре зур колач белән бара.

Без, башлангыч сыйныф укучылары, бу эштән читтә калмыйбыз. Шушы уңайдан сугыш һәм тыл ветераннарына медаль тапшыру тантанасында зур концерт күрсәттек. Сугыш истәлекләре турында бай материал тупладык. Бөек Ватан сугышы темасына карата рәсем, хикәя, кул эшләре күргәзмәләре оештырдык. II сыйныф укучысы Махубрахманова Чулпанның рәсеме, IV сыйныф укучылары Ибраһимов Исмәгыйль һәм Габдрахманов Азатның танк һәм самолёт модельләре югары бәягә лаек булды.




Зур бәйрәмгә багышлап, сыйныфлар арасында макетлар бәйгесе үткәрдек. I-II сыйныф укучылары “Билгесез солдат”, III сыйныфлар “Һәйкәл”, IV сыйныф укучылары “Тыныч булсын бөтен Җир шары!” макетларын, сугыш чорындагы “Победа” машинасы моделен ясадылар. Әлеге макетлар мәктәп дирекциясе һәм ата-аналар тарафыннан югары бәяләнде.

Бүгенге көндә без Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап класс сәгатьләре үткәрәбез, әдәби-музыкаль кичә әзерлибез,

укуда да сынатмыйбыз. Зур бәйрәмне лаеклы итеп каршылыйсыбыз килә.

Янга якын илләр күп шул,
Җанга якыны сирәк.
Туган илнең, туган жирнең
Кадерен белергә кирәк!

## АЧЫК ДӘРЕС

**Дәүләтшина Гөлсинә Габделвәли кызы,**
**Лаеш районы Нармонка урта мәктәбенең**
**беренче категорияле башлангыч класс укытучысы**

**Тема:** Антонимнар.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәр формалаштыру.

**Максатлар:**

**1. Белем бирү максаты** – синоним, омоним турындагы алдагы дәресләрдә алган белемнәрне искә төшерү, ныгыту, антоним турында төшенчә бирү.

**2. Фикер сәләтен үстерү максаты** – укучыларның сөйләм телен, логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын үстерүгә ярдәм итү, укучыларның үз фикерләрен тиз һәм төгәл әйтә белүләренә ирешү,) антонимнарның ни өчен кулланууларын билгеләү; телдән һәм язма күнекмәләр белән антоним, омоним һәм синоним турында белемнәрне ныгыту, шулардан чыгып нәтиҗә ясый белүләренә ирешү.

**3. Тәрбияви максат** – сугыш чоры кешеләренә, туган илгә хөрмәт хисләре уяту, аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен, кешелеклелек, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү; дәрестә балаларның тиз һәм дөрес җавап бирүләренә ирешү.

**Дәрес тибы**: яңа белемнәр формалаштыру дәресе.

**Җиһазлау:** Мультимедиа проекторы, слайдлар, индивидуаль эш дәфтәрләре, конвертта биремнәр.

**Кулланылган структуралар**: *МИКС ПЭА-ШЭА (Mix Pair Share), СИМАЛТИНИУС РЕЛЛИ ТЭБЛ (Simultaneos Rally Table), СИНГЛ РАУНД РОБИН (Singl Round Robin), КОНТИНИУС РАУНД РОБИН (Continuous Round Robin ). ЭЙ АР ГАЙД Хай Файв!, Конэрс , Мэнэдж Мэт.*

**Җиһазлау:** компьютер, проектор, "Татар теленең синоним, омоним, антоним сүзлекләре", дәреслек (Ч.М.Харисова, "Татар теле" 3 нче сыйныф), индивидуаль биремле карточкалар, тест биремнәре, проект төзү өчен рәсемнәр.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру моменты ХАЙ ВАЙФ.**

*Укучыларның дәрескә әзерлекләрен тикшерү.*

Хәерле иртә, Сезгә укучыларым! *Мэнэдж Мэт структурасы файдаланып,* әйдәгез, сез дә бер-берегезне сәламләгез. Башта иңнәр буенча күршегезне, аннары каракаршы торган дусларыгызны.

Яңа көн тынычлык алып килсен!
Яңа көндә яңа "5" леләр алыйк!
Әти-әниебезгә ягымлы булыйк!
Яңа көндә барыбыз да яхшы эшләр генә кылыйк
Бик яхшы. Утырыгыз
Матур үтсен көнегез!
Көләч булсын йөзегез!
Булыгыз сез әдәпле,
Тәрбияле, матур гадәтле.
Дөрес, матур утырыйк,
Тырышып җавап бирик.

**II. Белемнәрне актуальләштерү**

1. Фонетик зарядка.

Ә,Ү,Ж,ң,Һ,Ө.

2. Лексик зарядка.

Сугыш, мылтык, корал, ил чиге, ачлык, тынычлык, Ватан.

3. Дәфтәргә Кк хәрефен язу.

4. Орфографик минут.

Хәзер Сималтиниус Релли Тейбл структурасын файдаланып, карточкалар белән эшләп алырбыз. Һәрберегездә бертөрле карточкалар. Анда хәрефләре төшереп калдырылган сүзләр бирелгән. Күпнокталар урынына [о] һәм [ө] авазларын белдергән хәрефләрне куеп языгыз. Сезгә 1 минут вакыт бирелә.

1 нче карточка. Орч…к, төлк..., көнд...з, бор...н, көзг...., шом...рт, мөг...з, сол..., оз...н, көм...ш, бол...н. көчл..., йөз...м, дөр...с. (Ком сәгате куела.)

[о] һәм [ө] авазларын белдергән хәрефләрен язганда нинди кагыйдә не белергә кирәк?

[о] һәм [ө] хәрефләре беренче иҗектә генә языла, калган иҗекләрдә ишетелсә дә ы,е хәрефләре языла.

Карточкаларыгызны тикшерегез.

Үзбәя кую.

Орчык, төлке, көндез, борын, көзге, шомырт, мөгез, солы, озын, көмеш, болын, көчле, йөзем, дөрес. 4. Бу сүзләр турында нәрсә әйтә аласыз. (Класс, сыйныф; песи, мәче; өй, йорт)

Нинди сүзләр синоним сүзләр була? Сыйныфтагы иң озын кыз әйтә.

Мәгънәләре охшаш сүзләр синонимнар дип атала.

5. Бу сүзләр турында нәрсә әйтә аласыз? (кыңгырау, чаба, көзге).

Нинди сүзләр омоним дип атала?

Сыйныфтагы 1 майда туган кыз әйтә.

Әйтелеше белән язылышы бертөрле, ләкин мәгънәләре төрле булган сүзләр омонимнар дип атала.

Һәр өстәлдә конверт бар. Шул конверттан №2 дигән карточканы алыйк.

ЭЙ АР ГАЙД

Почмагына исемегезне язып куегыз. Карточкада сүзләрдә хәреф төшеп калган, хәзер сез шул төшеп калган хәрефләрне куеп чыгыгыз. (Вакыт бирелә.)

Ачлык та артта, суг...ш та артта,
Ил батырлары туган ул чакта.
Алда – т..н...члык, алда –гел к..яш,
Алда – гел к...лү,һич тә юк елаш.

Хай Файв!

Игътибар экранга. Слайдны карагыз. Сезнең фикерләр үзгәрдеме? Җавапларыгызны тагын бер кабат карагыз. Хаталарыгызны табыгыз. Төзәтегез. Бу өзектән синоним сүзләрне табыгыз.

*Укытучы:* Балалар, җавапларыгызны экранга карап тикшерегез.

Үзбәя кую.

Ачлык та артта, сугыш та артта,
Ил батырлары туган ул чакта.
Алда – тынычлык, алда – гел кояш,
Алда – гел көлү, һич тә юк елаш.

**III. Эшләп караган вакытта авырлыкны күрү.** Сезнең шигырь юлларында, сугыш, батыр, алда, көлү сүзләре бар, аларның кире мәгънәләре ничек була?

сугыш – тынычлык
батыр-куркак
алда-артта
көлү-елау

*Укытучы:* Бу сүзләр турында нәрсә әйтә аласыз, укучылар?

*Көтелгән җавап*: Бу сүзләр – антонимнар, алар капма-каршы мәгънәдә.

*Укытучы:* Димәк, без бүген дәрестә нинди тема үтәчәкбез?

*Көтелгән җавап:* Антонимнар.

Бүген безнең дәреснең максаты:

а) антонимның мәгънәсен аңлату;

б) антонимнарның ни өчен кулланууларын билгеләү

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

а) Рәсемнәрне чагыштырыгыз. Һәр
пар нинди сүз төркемендә булуын әйтегез.

зур – кечкенә(с)

кыш – җәй (и)

көн – төн(и)

озын – кыска(и)

киенә – чишенә(ф)

*б) Сорауларга нигезләнеп модель төзү.*

*Укытучы:* Ә хәзер сорауларга нигезләнеп белгәннәрне модельләштерәбез.

Алар нинди мәгънәдәге сүзләр? (Капма-каршы мәгънәдәге)

Нинди сүзләр антоним була ала? (Бер сүз төркеменә кергән сүзләр генә)

Антоним табуның алгоритмы

1.Сүздә капма –каршы мәгънәле.

2. Бер сүз төркеме булып килә.(исем, сыйфат, фигыль)

**V. Төзегән алгоритмны адымлап тормышка ашыру.**

Антоним сүзләрне табыгыз, нинди сүз төркеменә керүен бергәләп билгелибез.

VI. Физкультминутка. Микс – пэа – шэа структурасы.

Һәр өстәл урыннан тора, урындыкларны этеп куялар. Түгәрәк буенча җырлап баралар. Көй туктагач, сорауга җавабына карап басалар.

– Бүген атнаның ничәнче көне?(3)
– Сыйфат сүзендә ничә иҗек бар?(2)
– Алмагач сүзендә ничә сузык аваз бар?(3)
– Исем, сыйфат, фигыль – сүз төркемнәре. Җөмләдә ничә сүз бар?(5)

VII.Үзлектән эш, эталон буенча тикшерү.

71 нче күнегү. Антоним сүзләрне табып язырга. Һәрберегез күнегүне дәфтәрләрдә эшли.

СИМАЛТИНИУС РЕЛЛИ ТЭЙБЛ структурасы.

№1 нче белән № 3 нче һәм №2 нче белән №4 нче дәфтәрләрен алышып бер-берсенең эшен карандаш белән эталон буенча тикшерә.Фикер алыша.

1.Яхшы –яман.

2.Ап-ак –кап-кара.

3.Кыек-туры.

4.Әсир-җиңүче.

5. Үлем-яшәү.

Кемнең туганнары сугышта булган? Алар турында нәрсә беләсез? (Бер –ике җавапны тыңлау.)

**VIII. Алган белемнәрне ныгыту.**

1.72 нче күнегү. (Капма –каршы мәгънәдәге сүзләрне табарга, табышмакның җавабын язырга.) *Мэнэдж Мэт структурасы файдаланып,№1-1 табышмакның,№2 – икенче табышмакның , №3 –өченче табышмакның, №4 – дүртенче табышмакның җавапларын табып язарга.*

– Алар ни өчен кулланылган дип уйлыйсыз.

Көтелгән җавап.

– сөйләмнең сәнгатьлелеген көчәйтә.

– сүзлек хәзинәсен баета.

– контраст картиналар бирү өчен кулланылалар..

Конэрс структурасын файдаланып, почмакларга басыгыз. (Балык, урындык, “н” хәрефе, кәгазь һәм хәреф ) Нинди антонимнар таптыгыз?

2. Антонимнар мәкальләрдә дә бик күп кулланыла. Кем мәкальләр белә?

Батыр бер үләр, куркак мең үләр.

Аз сөйлә, күп эшлә.

Тырышлык – зур бәхет, ялкаулык – хурлык. Хезмәтнең тире ачы булса да, җимеше татлы .

*Тәмле тел таш яра, тәмсез тел баш яра.*

*Яхшы сүз-яз кебек, яман сүз-көз кебек.*
*Яхшы сүз дарулы, яман сүз агулы..*
*Акылы кысканың теле озын.*
*Яңа дустым булды дип иске дусны ташлама.*
*Уңган тимерченең куллары кара, ә икмәге ак.*
*Сүзнең кыскасы,бауның озыны яхшы.*
Былтыр кысканга,быел кычкырмыйлар
Яхшыны ишетәсең килсә,яман сөйләмә.
Аз эш күп сүздән яхшырак.
Туры әйткән, котылыр,
Ялганлаган тотылыр.
Бер ялган сөйләсәң –тугыз дөресеңә дә ышанмаслар.
3.Шигырь юлларыннан синонимнарны табарга.
Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә.
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә.
Тезгә куеп сезгә хатлар язам
Сугыш тынган алсу таңнарда.
Балаларым ,сезне үбеп калам
Сәлам сезгә - сөйгән ярларга.
Саф мәхәббәт белән язган хатың
Йөрәкләргә дәрт һәм көч бирә.

Ярсып- ярсып атам һәр пулямны,
Ватан өчен, туган ил өчен,
Балам өчен, атам – анам өчен,
Назлап сөйгән ил өчен.

4. Проект “Синоним һәм омонимнар шагыйрьләр иҗатында”. Һәрбер төркемгә рәсемнәр таратылган, хәзер сез синоним, омоним һәм антонимнарга мини –проект төзисез һәм ул проектны яклыйсыз.

**IX. Рефлексия.**

*Тест*

1. Антонимнар дип нинди сүзләргә әйтәләр?

а) мәгънәдәш сүзләргә;

б) капма-каршы мәгънәдәге сүзләргә;

в) охшаш сүзләргә.

2. Нинди сүзләр антоним була ала?

а) төрле сүз төркеменә кергән сүзләр;

б) язылышлары бер төрле булган сүзләр;

в) бер сүз төркеменә кергән сүзләр генә.

3. Җылы сүзенең антонимын табыгыз

а) матур

б) салкын

в) кечкенә

*Үзбәя.*

Укытучы: Тест биремнәренең җавапларын экранга карап тикшерегез һәм билге куегыз. Бер хатасыз эшкә – “5”ле, бер хаталы эшкә – “4”ле, ике хаталы эшкә – “3”ле.

Укытучы: Молодцы, укучылар. Сез бүгенге дәрестә бик актив булдыгыз, билгеләр үзбәягә карап куела.

**X. Өй эше.**

Антонимнарны кертеп сугышта булган туганнар турында хикәя язырга. Дәресне шундый сүзләр белән тәмамлыйсым килә:

*Сәламәт булыгыз!*
*Бәхетле булыгыз!*
*Кояш кебек балкыгыз!*
*Йолдыз кебек яныгыз!*
*Чишмә кебек саф күңелле булыгыз!*
*Күбәләкләр кебек шаян булыгыз!*
*Кырмыскалар кебек эшчән булыгыз!*
*Зур үсегез, чын кеше булыгыз!*

## РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ ДӘҮЛӘТ СИМВОЛЛАРЫ (2-3 сыйныфлар өчен сыйныф сәгате)

**Туктарова Роза Шакирҗан кызы,
Түбән Кама районы Кама Аланы 1нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең югары категорияле башлангыч сыйныф укытучысы**

**Максат:** укучыларны Россиянең дәүләт символлары белән таныштыру. Туган ил, кече туган ил төшенчәләрен ачыклау, белемнәрен баету; патриотизм, горурлык хисе, туган илгә мәхәббәт, аның символларына сакчыл караш, социаль норма һәм кыйммәтләргә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:**

– мультимедиа (презентация)

– төрле конструкторлар, төсле каты кәгазьдән киселгән фигуралар

– альбом битләре, төсле карандашлар

– Россия гимны язмасы

– викторина сораулары

Чараның барышы

Теманы актуальләштерү.

1. Төркемнәрдә укучыларга билгеле бер вакыт арасында әзер детальләрдән йорт "төзергә" тәкъдим ителә *(алдан хезмәткә өйрәтү дәресләрендә каты төсле кәгазьдән детальләр әзерләргә мөмкин, яки әзер конструкторлар файдаланыла.)*

– Укучылар, сез үзегезгә ошаганча матур итеп йортлар төзедегез. Рәхмәт! Һәр бина үзенчә матур һәм кызыклы.

(Төркем җитәкчеләре үзләренең корылмалары, йортлардагы уңайлыклар турында чыгыш ясыйлар).

Әйе, сезнең һәрберегезгә әлеге өйләр, үзегез яшәгән

йорттай кадерле һәм әһәмиятле. Кешенең туып-үскән урынын ничек дип атыйлар әле? *(Укучылар җаваплары тыңлана.)*

2. Туган ил турында көй (җыр) астында слайдларда туган як табигате күренешләре төшерелгән рәсемнәр күрсәтелә *(укытучы презентация өчен көйне үзе сайлый; слайдлар автоматик рәвештә алышына)*.

“Туган илем – иркә гөлем” әңгәмә.

– Туган илне тагын ничек атап була?

– Туган ил, туган як, туган җир, Ватан, Ватан-ана.

***Слайд 12*** *(Татарстан картасы күрсәтелә)*. Әйе, безнең Татарстан республикасы чиксез бай һәм матур. Ул бөек Россия киңлекләрендә урнашкан. Монда бик күп милләт халыклары дуслыкта һәм бердәмлектә матур гомер кичерә. Аларның бай гореф-гадәтләре, борынгы культуралары туган ягыбызның иң мөһим рухи байлыгы.

Һәркемгә үз туган ягы йөрәгенә бик якын һәм кадерле. Кайда гына булсаң да, нинди генә матур җирләрне күрсәң дә күңел барыбер үз туган ягыңа тарта, чөнки монда табигать тә матуррак, һава да чистарак. Бездәге яшел куе урманнар, саф сулы чишмәләр, Идел, Чулман, Нократ елгалары һәркемне таң калдыра.

Туган як – ул безнең яраткан гаиләбез һәм туган йортыбыз гына түгел, туган ягыбыз – безнең бөтен Татарстан. Анда күп гасырлар буе безнең ата-бабаларыбыз яшәгән, безгә мирас итеп гореф-гадәтләрен, туган телебезне калдырган.

*(Россия картасы, анда Мәскәү һәм Казан шәһәрләре аерым төс белән күрсәтелгән)*

– Ә кече Туган илебез Татарстан кайда урнашкан? ...

– Әйе, алда әйтелгәнчә, ул бөек Россия киңлекләрендә урнашкан. Россия – иксез-чиксез зур дәүләт. Аның составына 89 субъект керә.

- 21 республика

• 49 өлкә
• 1 автономияле өлкә
• 10 автономияле округ
• федераль дәрәҗәдәге ике шәһәр (Мәскәү һәм Санкт-Петербург)

– Ә илебездә күпме халык яши? *(Алдан әзерләнгән укучыга сүз бирелә).*

– 2010 нчы елда узган халык санын алу вакытындагы мәгълүматларга караганда, бөек Россия халкын 141 миллионнан артык кеше тәшкил итә. Илебездә 180нән артык милләт халкы һәм төрле этник төркемнәр яши.

– Россия – ул руслар, татар, башкорт, чечен, коми, удмурт, марый һәм башка халыклар.

– Кадерле укучылар, йортлар төзегәндә сез үзегезгә ошаган төрле матур детальләрне сайладыгыз. Бергә киңәшләшеп, сез берсеннән-берсе матур, кабатланмас йортлар кордыгыз.

Ә Россиядә яшәүчеләрне кемнәр дип атыйлар? Без – Россиялеләр.

**IV. Россия символикасы.**

– Дөньядагы барлык дәүләтләрдәге кебек Россиянең дә үзенең дәүләт символикалары бар: флаг, герб, гимн.

**1. Россия флагы.**

– Россия флагы нинди төсләрдән тора?

– *(Алдан әзерләнгән укучы чыгышы)* Һәрвакытта флагның төсенә аеруча игътибарлы булганнар. Ак төс – тынычлык һәм чисталык символы, зәңгәр – күк йөзе, тугрылык һәм дөреслек, кызыл – ут һәм куркусызлык билгесе.

Ак, зәңгәр, кызыл төсләр элек-электән милли киемнәрдә файдаланылган. Ак ефәк тукымадан күлмәкләр, кызыл һәм зәңгәрдән матур-матур сарафаннар һәм башка төрле киемнәр теккәннәр.

**2. “Флагны таны (тап)” уены.** *Балаларга төрле*

*дәүләтләрнең флаг рәсемнәре күрсәтелә.*

– Россия флагын табыгыз.

– Башка флаглардан ул нәрсәсе белән аерыла? Сез аны кайларда күрәсез?

– Әйе, Россиянең Дәүләт флагы илебезнең җитәкче органнары урнашкан биналарда даими эленеп тора. Флаг шулай ук тантаналы чаралар, бәйрәмнәр вакытында күтәрелә. Россия корабльләренең мачталарында шулай ук флаг җилферди. Ә менә ил буенча кайгылы көннәр – траур булса, флаг төшерелә яки таякның өске ягына кара лента бәйләнә.

**3. Россия гербы.**

– Дәүләтебезнең гербы зур эстетик зәвык белән эшләнгән символик билге. Аңа, сәнгать әсәренә карагандай, сокланырга мөмкин, ә иң әһәмиятлесе аны дөрес итеп укый белү.

2000 нче елның декабрендә Дәүләт Думасы Россия Федерациясенең дәүләт символлары турында закон кабул итте. Шулай итеп, өченче меңьеллыкка Россия яңа дәүләт символлары белән аяк басты. Бу законда гербка түбәндәге характеристика бирелә: Россиянең дәүләт гербы – аскы почмаклары түгәрәкләнеп, уртасы очланып киткән, канатлары өскә күтәрелгән ике башлы бөркет сурәте төшерелгән турыпочмаклы кызыл калкан формасында. Бөркетнең ике башында ике кечкенә таҗ, алар лента ярдәмендә зур таҗга беркетелгән. Аның уң аягында-скиптер, сул аягында – дәүләт. Бөркетнең күкрәгендә, кызыл калканда көмеш атка атланган, зәңгәр плащлы аяк астында чалкан яткан аждаһаны аты белән таптаткан көмеш җайдак сурәтләнгән. Гербны эшләүче художник – Е.И. Ухналев. Шулай итеп, яңа өченче меңьеллык башында 500 еллык тарихы булган дәүләт эмблемасы яңадан туа. Гербта ике башлы бөркет – Россия Федерациясенең бәйсезлеген, Европа һәм Азия өлкәсе халыкларының бердәмлеген символлаштыра.

– Укучылар, ә сезнең Россия гербын кайларда күргәнегез бар? *(Безнең илебезнең җитәкчеләре эшли торган биналарның алгы ягында, дәүләт документларында, паспортта.)*

**4. Төркемнәрдә “Безнең өйнең гербы” уены.** (Балалар үзләре төзегән өйләренә герб ясыйлар һәм мәгънәсен аңлаталар.)

**5. Россия гимны.**

– Дәүләт хөрмәтенә язылган тантаналы музыкаль әсәрне гимн дип атыйлар. “Гимн” сүзе грекча ”тантаналы мактау җыры” дигәнне аңлата. Аның музыкасы һәрвакыт тантаналы, күтәренке рухлы, хисчән яңгырашлы. Дәүләт гимнының авторлары – композитор Александр Александров һәм шагыйрь Сергей Михалков.

*Россиянең Дәүләт гимны яңгырый.*

**V. “Президент сайлаулары” – әңгәмә.**

– Һәр дәүләтнең баш шәһәре бар. Россиянең башкаласы нинди шәһәр?

– Нәкъ башкалада илнең хуҗасы, төп кешесе – президент Дәүләт белән идарә итә. Россиянең президенты кем?

– Президентның вазифасы нәрсәдән гыйбәрәт?

– Кем президент була ала? *(Россия Федерациясенең президенты итеп 35 яше тулган һәм 10 ел дәвамында Россия җирлегендә даими яшәгән Россия гражданины сайлана ала.)*

– Хатын-кыз президент була аламы? *(Әйе, әгәр 35 яше тулган һәм 10 ел дәвамында даими Россия җирлегендә яши икән.)*

– Президентны кем сайлый? *(Россия Федерациясенең Президентын, сайлауга хокукы булган һәр кеше дә сайлый ала.)*

– Президент итеп сайланучы нинди кешелек сыйфат-

ларына ия булырга тиеш? ..

– Укучылар, сез тырышып, зур көч куеп өй төзедегез. Моның өчен сезгә тырышлык, күпмедер вакыт, түземлелек кирәк булды. Әгәр кемдер килеп, өегезгә хуҗа булырга, аны җимереп, сезгә ошамаган ямьсез, уңайлыклары булмаган башка йорт төзергә теләсә?

– Димәк, президент постына сайланган кеше башкалар корган кыйммәтләрне, элек төзелгәнне саклап, хөрмәт итеп, яңа файдалы эшләр күрсәтергә тиеш. Ә бары күмәк эшләнгән эш кенә зур уңышларга китерә, күп кешегә файда итә. Игътисадта да шулай ук – фикерләр һәм кылган гамәлләрдә, һичшиксез, бердәмлек кирәк. Президент үз командасы белән киңәшләшеп, ил халкының ихтыяҗларын канәгатьләндерүне күздә тотып эш итә.

**VI. Рефлексия. Дәрестә бирелгән мәгълүматларны ныгыту максатыннан викторина үткәрелә.**

– Безнең илебез ничек атала?
– Кайсы шәһәр Россиянең башкаласы булып тора?
– Дәүләт белән кем идарә итә?
– РФ символларын ата.
– Россия Дәүләт гербында нәрсә сүрәтләнгән?
– Россиянең Дәүләт флагының төсләрен атагыз.
– “Гимн” сүзе нәрсәне аңлата?
– Син яшәгән Республиканың исеме ничек?
– Россия президентын атагыз.
– Россия Дәүләт гербын кайда күрергә мөмкин?
– Татарстан Республикасының Дәүләт флагының төсләрен атагыз.
– Тантаналар вакытында гимны ничек тыңлыйлар?

Сыйныф сәгате Россия Федерациясе һәм Татарстан республикасы Дәүләт гимннарын тыңлау белән тәмамлана.

# ИЛ САКЛАР ИР БУЛЫП ҮСЕГЕЗ!
## (Фатих Кәримнең “Пионерка Гөлчәчәккә хат” поэмасы буенча дәрес-фикерләмә, 8 нче сыйныф)

**Хафизова Рушания Хәлил кызы,**
**ТР Саба муниципаль районы И.С.Башкиров исем. Завод-Нырты урта гомуми белем бирү мәктәбенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Максат:** 1) Дидактик – язучы турындагы белемнәрен баету, поэманы укучыларга тирәнтен аңларга өйрәтү.

2) Үстерешле – тема буенча фикерләү ысулларын формалаштыру.

3) Тәрбияви – әсәрдәге геройлар үрнәгендә патриотизм тойгысы, гражданлык хисләре тәрбияләү; фикерләү сәләтләрен үстерү.

**Җиһазлау:** Ф.Кәримнең “Пионерга Гөлчәчәк хат” поэмасы; кызыл галстук; чиккән кулъяулыклардан күргәзмә; Васыять” язылган истәлек-хатлар; Ялкын” журналы, 2007ел, октябрь.

**Дәрес төре:** дәрес-фикерләмә.

**Предметара бәйләнеш:** тарих, җыр.

**Метод һәм алымнар:** әңгәмә, индивидуаль һәм дефференциаль эш.

**Дәрес барышы:**

1. Мотивлаштыру-ориентлаштыру

**Укытучы.**

Батырлыкны эшли ала
Бөтен кеше дә.
Аның өчен кирәк түгел
Алып көче дә.
Ә моның өчен:
Яратырга кирәк бары

Туган җиреңне,
Әтиеңне-әниеңне,
Туган илеңне!

Р.Миңнуллинның бу шигъри юлларын дәрестә без үзебезгә юлдаш итеп алырбыз, аның мәгънәсенә төшенергә тырышырбыз.

**Максатыбыз:**

– Ф.Кәримнең ”Пионерка Гөлчәчәккә хат” поэмасы аша безгә нәрсә әйтергә теләгән аңларга тырышырбыз.

– Кем ул патриот? Кем ул пионер? Шушы сорауларга җавап эзләрбез.

– Ә сез туган илне сакларга әзерме? Шул турыда да уйланырбыз.

– Укучылар, бүгенге дәрестә без төркемнәргә бүленеп эшләрбез. Киләчәктә сез төрле һөнәр ияләре булырсыз. Ә бүгенгә:

1 төркем – тарихчылар.
2 төркем – язучылар.
3 төркем – рәссамнар.

Поэманың авторы Ф. Кәримнең сугыш чорындагы батырлыклары турында без беләбез.

Моны тарихчылар ничек бәяләр икән?

**“Тарихчылар” төркеме**

Ф.Кәрим 1939-1941 елларда нахакка рәнҗетелеп төрмәдә утыра. 1941 елның 1 декабренда тулысынча аклана һәм берничә атнадан үзе теләп фронтка китә. Сугышның соңгы айларына кадәр алгы сызыкта була, өч тапкыр яралана. Батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә. Тик ул туган илгә әйләнеп кайта алмый. Сугыш бетәргә аз гына калгач, 1945 елның 19 февралендә батырларча һәлак була.

“Пионерка Гөлчәчәккә хат” әсәрен 1942 елда яза.

**Укытучы**. Чыннан да, Ф.Кәрим сугыш чорында Мәскәүдән алып Көнчыгыш Прусиягә кадәр юл уза. Украинаны, Белоруссияне азат итүдә катнаша. Гади солдаттан взвод командиры дәрәҗәсенә күтәрелә. Сугыш бетәргә санаулы гына көннәр калгач, сугышчан бурыч үтәгәндә һәлак була. Аның гәүдәсе Калининград өлкәсендәге Победа туганнар каберлегенә күмелгән.

Бүләкләре:

– Беренче дәрәҗәдәге Ватан сугышы ордены, Кызыл Йолдыз ордены

**Укытучы.** Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, нәрсә ул сугыш?

Җаваплар:

– Минемчә, сугыш – ике илнең килешә алмыйча яшәве, бер-берсенә каршы чыгуы.

Сугыш – күз яшьләре, үлем, фаҗига. (Укучыларның җаваплары тыңлана.)

**Укытучы.** Әйе, укучылар, сугыш ул - җимерүче, күз яшьләре түктерүче, миллионлаган кешеләрнең гомерен өзүче. Ф.Яруллин “Сугыш ул – акыллы кешеләрнең акылсыз эшләре” дип язган.

Безнең районнан Бөек Ватан сугышына 12 мең кеше китә. Ә безнең җирлектән китүчеләр саны 414. Шулар арасыннан - 21е хатын–кыз. Сугыш кырыннан 148 кеше әйләнеп кайта, ә 245 кешегә кайту насыйп булмый.

Безнең мәктәп каршысында бер бюст тора. Ул безнең якташыбыз Советлар Союзы Герое Иван Сергеевич Башкиров истәлегенә куелган. (Экранда рәсемнәр күрсәтелә.)

– Аның турында ниләр беләсез?

Безнең районда 4 Советлар Союзы Герое бар. Район үзәгендә алар истәлегенә мәңгелек ут яна.

**Укытучы**. Ф.Кәрим сугышка кадәр дә, сугыш чорында да бик күп иҗат иткән.

Сугыш елларындагы иҗаты турында язучылар нәрсә әйтер икән?

**“Язучылар” төркеме**

- Фронтның авыр шартларында да Ф.Кәрим бертуктаусыз иҗат итә. Ул шушы чорда 9 поэма, 2 повесть, 1 драма әсәре, 100 шигырь яза.

**Укытучы**. Шул чорда язылган әсәрләрен санап китә аласызмы?

– “Үлем уены”, “Кыңгыраулы яшел гармун”, “Партизан хатыны”, “Гөлсем”, “Газиз әнкәй”, “Шомырт кулагы”, “Ант”, һ.б.

**Укытучы.** Ф.Кәрим фронттан җибәрелгән бер хатында: ”Сугышта шунысы кыйммәт, бөтен нәрсәне йөрәгең аша үткәрәсең. Минем язган әйберләрем уңышлы икән, моның сәбәбе шушы: канымны коеп сугышам, шуның турында шул хисләр белән язам,” – дип хәбәр итә.

**“Кыңгыраулы яшел гармун”** поэмасыннан өзек. (Бер укучы сөйли)

**Укытучы.**

– Укучылар, нәрсә ул поэма?

– Әсәрнең исеме “Пионерка Гөлчәчәккә хат” дип атала. Ә сезнең хат язганыгыз, я булмаса алганыгыз бармы?

– Кемнәр белән хат алышасыз?

– Нәрсә ул хат?

**Укучы.** Хат ул – нәрсә дә булса хәбәр итеп, хәл-әхвәлеңне, үз фикерләреңне, хисләреңне белдереп, кемгә дә булса атап языла торган язу. Аны почта аша конверт белән җибәрәләр.

**Укытучы.** Бүгенге көндә нинди аралашу чаралары бар?

Укучыларның җаваплары тыңлана.

Сугыш кырыннан җибәрелгән өчпочмаклы хат күрсәтелә.

– Балалар, әниләр өчен иң кадерле хатлар кемнәрдән килгән хатлар дип уйлыйсыз?

– Солдат улыннан.

Татар егетләре Бөек Ватан сугышы елларында да үзләренең кыюлыклары, фидакарьлекләре белән аерылып торганнар. Безнең егетләр хәзер дә сынатмыйлар, илебезнең төрле төбәкләрендә хезмәт итәләр.

Бүген көндә безнең авылдан 2 егетебез, Гәрәев Нәфис һәм Фәләхов Ришат, Ватан алдындагы изге бурычларын үти. Минем кулымда солдат хатлары. (Хатлар укыла.)

